Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 17 (1433) 5 май 2023 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8

Полковник Барый Йосыпов яу кырларында реактив минометлар кулланган тәүге командирларның берсе буларак тарихка керә.

12

1941-1943 елларда Татарстанда оештырылган җиде дивизиянең дүртесе Белоруссияне саклап калу һәм азат итү өчен канлы яуларда катнашкан.

16

Мөхәррәм Галимов исемен иштү белән алман очучылары радиоэлемтә аркылы: «Сак булыгыз! Һавада Галимов очучылары!» – дип бер-берсен кисәтә торган булган.

Илнең азатлыгын яклап җиңү – Күктән иңдерелгән бурычтыр!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Уфа дәүләт татар театры «Нур» актрисасы Гөлназ Мөхәммәдиевага Татарстанның атказанган артисты исемен бирде.

- Быел «Тяжело с татарским» антипремиясен IT-парк һәм «Иске шәһәр префектурасы» алды.

- «Россиянең ел укытучысы» бәйгесе җиңүчеләре 1 миллион сум күләмендә приз ала башлаячак, призерларга 500 мең сум түләячәкләр.

- Башкортстан Башлыгы Радий Хәбиров тәкъдиме белән республикада генерал Шәйморатов медале гамәлгә куелды.

- Түбән Новгород өлкәсе татар милли оешмалары 2023 елны Түбән Новгород өлкәсендә җырчы Рәшит Ваһапов елы дип игълан итте.

- Түбән Каманың Габдулла Тукай исемендәге Үзәк китапханәсендә язучы Гөләндәм Галиеваның «Канатлы нур» китабын тәкъдим итү кичәсе узды.

- Дубайда 17 илдән татар активистлары катнашында узган конференциядә Әлфия Бәдретдинова гарәп илләрендә яшәүче татарлар берләшмәсенең рәисе итеп сайланды.

- Самарада узгән «Мирас» татар мәдәнияте халыкара фестивалендә Россия төбәкләреннән, Швеция, Чехия, Канада, АКШ, Казахстан кебек чит илләрдән 500 дән артык кеше катнашты.

- Казан кызы 11 яшьлек Ралина Ибраева Казахстандагы «Qazaqstan Даусы. Балалар» шоу-проектында «Туган тел»не җырлап чираттагы турга кабул ителде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Васил ШӘЙХРАЗЫЕВ, Татарстан премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе:

«Кеше бәлки телсез була аладыр, ләкин милләт телсез була алмый. Татар халкы меңләгән еллар яшәп, үз телен, милләтен саклап кала алган икән, бүген дә ул безнең төп бурыч. Шәҗәрә буенча җиде буынны белергә кирәк, дибез. Аны белү генә аз. Аны балаларның, оныкларның йөрәкләренә салырга кирәк».

СЫНАМЫШЛАР

●6 майда яңгыр яуса, терлек-туар өчен уңышлы ел көтелә, әмма карабодай уңмаячак; кичен һәм төнлә аяз булса, җәй коры килә, игеннәр уңа; кырау төшсә, тагын кырык тапкыр кырау төшәр, дип фаразлана; чөгендер һәм кишер чәчәргә була●11 майда төн йолдызлы һәм җылы булса, игеннәр уңа.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 54 минутта** чыкты, һәм ул **19 сәгать 28 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **15 сәгать 34 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **29 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **12 майда 16 сәгать 03 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

5 май – шагыйрь, язучы, публицист Зариф Шәрәфетдин улы Бәширинең тууына 125 ел (1888–1962);

– рәссам, график Флүс Нурулла улы Төхфәтуллинга 75 яшь (1948).

7 май – җырчы, Татарстанның халык артисты Рәшит Ваһап улы Ваһаповның тууына 115 ел (1908–1962).

9 май – актёр, Татарстанның халык артисты Гата Исай улы Нуруллинның тууына 100 ел (1923–2001).

10 май – язучы Гариф Закир улы Галиевнең тууына 120 ел (1903–1985).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Майның магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көнне исегезгә төшерәбез: 9 май.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(5-12 май)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген шәүвәл аеның 15 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Иршад ГАФАРОВ

СУГЫШТА ЮЛБАРЫСТАН КӨЧЛЕ ХАЛЫК...

Быел икенче Бөтендөнья сугышы тәмамлануга 78 ел тула. Җиңүгә илебез керткән өлешне санап бетереп булмаслык, чөнки ул фашизмны тар-мар итүдә төп рольне үтәде. Тик соңгы елларда еш кына: «Җиңү рус солдатларының батырлыгы, рус халкының фидакяр хезмәте аркасында мөмкин булды», – дигән сүзләр ишетәбез. Бу тарихи дөреслеккә туры килми, биредә совет халкы тарафыннан фронтка бөтен нәрсәне җитәрлек алган совет солдатының батырлыгы аркасында яуланды дигән әйтем урынлы булыр иде. Ул чорда Гитлер һәм аның тарафдарлары бик теләсәләр дә, төрле милләтләргә бүленү булмады. Ил алдында куркыныч туганда, халкыбыз бердәм булып дошманга күтәрелде. Хәзерге вәзгыять моның ачык мисалы булып тора һәм шуңа да без «россия сугышчылары» дигән сүзләрне ешрак ишетәбез.

Фикеребезне саннар белән раслыйк. Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен СССРдагы 70тән артык милләт вәкилләренә Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исем бирелде. Биредә әлеге исемгә ике тапкыр лаек булган атаклы очучы Әмәтхан Солтан сүзләрен китерү урынлы: «Мин татар герое да, лак герое да түгел. Мин – Советлар Союзы Герое. Ә кем улы? Әти һәм әнинеке. Аларны берсеннән берсен аерып буламы?»

Геройлар арасында 8160 рус, 2089 украиналы, 309 белорус, 161 татар, 108 еврей, 96 казах, 91 грузин, 90 әрмән бар. Шулай ук 25 кеше – Дагстан халыклары вәкиле, 7(8) кырым татары, 8 бурят, 8 кабардин, 4 француз, 11 немец, 4 поляк һ.б. Тагын республикабыздан 183 кеше, шулар арасында шактый татар, бу бүләккә тәкъдим ителсә дә, аларга бирелмәде. Әйтик, күкрәкләре белән дошман амбразурасын 13 татар каплаган булса да, аларның берничәсе генә герой исемен ала. Шул исәптән Л.И. Брежнев китабында искә алынган Тәтеш районыннан Сәләхетдин Вәлиуллловка да орден гына бирәләр. 1947 елның 1 ноябренә барлыгы 193 милләт вәкилләре орден һәм медаль белән бүләкләнгән.

Александров исемендәге бакчадагы мәңгелек ут янында: «Беркем дә, бер нәрсә дә онытылмады!» – дигән язу бар. Шулай булгач, ни өчен телевидение каналларында, бигрәк тә Россиядән читкә эшләгәннәрендә, Җиңү көненә әзерләнгәндә генә булса да, теге яки бу милләтнең батыр улларына һәм кызларына багышланган тапшырулар оештырмаска? Шул исәптән кайчандыр СССРда яшәгән украинлылар, белорус, казах, грузин, азәрбайҗан һ.б. турында. Бу бүгенге ил җитәкчеләрендә борчу тудырган мәсьәлә – патриотлык һәм интернациональлек рухы тәрбияләүгә кертелгән зур өлеш булыр иде. Бер үк вакытта бу һәр көн телевидение экраннарында буталган буш куыклар һәм алдакчылар авызын капларлык чүпрәк тә булыр иде.

Моны көн саен, берничә каналда чит кешеләрнең эчке киемендә казыну, кемнең ничә тапкыр иренә яки хатынына хыянәт иткәне турында, өч-дүрт баласының этиләре кем икәнен белмәгән аналарны күрсәтү, алар турында сөйләү урынына күрсәтсәләр, файдасы да күпкә яхшырак булыр, бәлки.

Сугыш чорында инде хәзерге сөйләмнән юкка чыгу дәрәҗәсенә җиткән интернационализм рухы көчле булган, бары тик җырдагы сүзләрне генә искә алырга мөмкин: «Каткан ипи кисәген дә урталай...» Биредә сирәк очрый торган мисалны атап китәсе килә: 1944 елның 23 июнендә Витебск өлкәсенең Орша районында украиналы Ильченко һәм татар Бари Шәвәлиев икәүләп дошман дзотының амбразурасын томалый. Алар ике бертуган кебек, газиз җирне үзләренең каннары белән чылатып, үлемсезлеккә атлый. Икесе дә, үлгәннән соң, Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Эзтабар Р.Х.Насыйров А.Матросов турында мәгълүматлар эзләү буенча шактый зур эш башкара. Күпләгән мәгълүматлар, фотографияләрне чагыштыру нигезендә, ул аның Башкортстанның Өчиле районы Кунакбай авылыннан татар Шакирҗан Юнус улы Мөхәммәтҗанов икәнен белде. Моны эксперт-галимнәр дә раслады.

Берничә ел элек президент үзенең юлламасында авырлыкның күп өлешен үз җилкәсендә рус халкы алып чыкты дигән иде. Бу турыда беркем дә бәхәсләшми. Мин әле мәктәп елларыннан ук математика барлык фәннәрнең алиһәсе дигән гыйбарәне хәтерлим. Шуңа да кайбер саннарга мөрәҗәгать итәсем килә, чөнки бөтен нәрсәне чагыштыру аркылы белеп була.

1939 елда СССРда 99 591 520 кеше рус милләтеннән була, шулардан 5756600 яу кырында ятып кала. Бу гомуми халыкның 5,78 % тәшкил итә. Украиналылар югалтуы 4,89% (28111007-1377400), белоруслар 4,79% 5275393-252691), еврейләр 4,7% (3028538 -142500), татарлар – 4,35% һ.б.

Татарлар турындагы мәгълүмат дөрес түгел. «Хәтер» китабында язылганча, фронтка Татарстаннан 700 меңнән артык кеше чакырыла (бөтен халыкның 24%), шулардан яу кырында 370 меңе ятып кала (соңгы мәгълүматлар буенча 388 мең), бу – барлык чакырылышның яртысыннан да артык.

Статистикадан билгеле булганча, 1939 елда Татарстанда 2915277 кеше саналып, шулардан 1421514 е татарлар була, бу 48,76%. Димәк һәлак булучы якташларның 170660 ы – татарлар. Бу республикадагы татарларның 12 % (!).

Фикеребезне дәвам итик. 1939 елда СССРда 4313488 татар милләтеннән булган кеше саналган, димәк республикадан читтә 2891974 (67,04%) татар яшәгән. Кривошеев китабыннан күренгәнчә, сугышка 1700 мең татар чакырылган (бу барлык татарларның 34,4%), димәк илебезнең бөтен төбәкләреннән 1358680 (79,9%) татар яуга киткән. Аталган автор мәгълүматыннан күренгәнчә, сугышта 187700 татар һәлак булган. Язганыбызча, 187700 һәлак булган татарның 170660ы Татарстаннан булгач, бөтен төбәкләрдән сугышка чакырылган 1 млн 359 мең татарның бары 17040 гына яу кырында калган булып чыга? Бу бары 1,25% кына. Билгеле, бу бернинди кысаларга да сыймый! Бу дөреслеккә дә туры килми!

Әгәр бөтен төбәкләрдән чакырылган татарлардан һәлак булучылар 4% кына дип алсак та (54347), тулаем татарларның югалтуы 5,216% (4313488 -225007) булачак. Бу руслардан кала, икенче күрсәткеч булыр иде. Шуны да искәртик, руслар, украин, белоруслар үз өйләре тирәсендә сугышса, татарларга гаиләләреннән һәм «кече ватан»нарыннан еракта башларын салырга туры килде. Бу урында Сталин генералларының бертавыштан: «Татарлар – иң яхшы солдатлар!» – дип язуларын гына искә алмый булмый.

Укучыларның игътибарын тагын бер тарафка юнәлтик. Республикада җиде дивизия, йөзләгән аерым марш роталары оеша. 225 якташыбыз Герой исеменә, 50 Дан орденының тулы кавалеры була, 200 меңнән артыгы орден һәм медаль белән бүләкләнә. Шул ук вакытта татарларга дәрәҗәләр, бүләкләрне бирергә бик ашыгып тормауны да искәртергә кирәк. Бу турыда мисаллар нигезендә күп тапкырлар искә алынды.

Республиканың Ватан сугышында җиңүгә керткән өлеше турында күп яздылар, Казанга «Фидакяр хезмәт каласы» дигән мактаулы исем дә бирелде. Бөек Ватан сугышы елларында Республика армияне кирәк-ярак белән тәэмин итү үзәгенә әйләнде. Фронт өчен барлыгы 600 ләп төр продукт җитештерелде. Хәзер Украинада барган хәрби вәзгыятьтә катнашучыларның балаларына, гаиләләренә дәүләт тарафыннан шактый күп ташламалар бирелә, алар моңа лаек.

Тик күңелдә бер төер кала. Чын «сугыш балалары» һаман хөкүмәтебез игътибарыннан читтә кала бирә. Ә бит аларның иң кечесенә дә быел 78 яшь тула. Хөкүмәт җитәкчеләре дә, Дәүләт Думасы депутатлары да «сугыш балалары» да, аларның балалары да түгел, югыйсә бу турыда сүз кузгатырлар иде. Дөрес, илебезнең 30 лап төбәгендә аларга күпмедер ташлама кертелгән, ә күпме генә «Без булдырабыз!» дип күкрәк каксак та, республикада аларны олуг бәйрәм белән котлау өчен открыткалык та акча юнәлтә алмыйлар. Ә шул ук вакытта дистәләгән спорт клубларына уенчылар сатып алырга, аларга гади кешенең төшенә дә кермәгән күләмдә хезмәт хакы түләргә, кием-салым, уен өчен кирәк-ярак алырга миллиард сумнар табыла.

АДЫМ-АДЫМ – ЮЛ БУЛЫР...

Бүгенге глобаль кризис шартларында хәятны киң мәгънәдә Аллаһ кануннарына туры китереп үзгәртүнең (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүнең) озын, әмма иң ышанычлы һәм реаль юлы – метасәяси борылышны түбәннән югарыга (шәхес-мәхәллә-нәзарәт-өммәт-диннәр) кору, дидек. Әзерлеге җитәрлек булган (хак динебезнең тәүхиди-иҗтиһади асылын ислам метафизикасы дәрәҗәсендә аңлаган) мөэминнәр өчен андый борылыш механизмы шәхси планда бик гади: бүгеннән үк (һичкемне көтеп тормастан), тотасың да, киң мәгънәдә илаһият кануннары буенча яши башлыйсың. Сүз, әлбәттә, дини йолалар үтәү турында гына түгел (гәрчә, алары да бик мөһим эш), ә яшәү рәвешеңне үзгәртү һәм абсолют кыйммәтләр системасына күчеп яши башлау турында да бара. Гаиләңдә дә шундый ук яшәү рәвешенә ирешәсең, аның асылын башкаларга да аңлатасың һәм алар өчен үрнәк булырга омтыласың. Үз тирәңдә таныш-белешләр һәм социаль челтәрләр аша теләктәшләр туплыйсың, рухи үсеш юлында алар белән теләктәшләр төркеменә берләшәсең, төркемнең аң-белемен күтәрү юлында иҗтиһат итәсең. Рухи үсешнең формуласы: теләктәшләр-фикердәшләр-рухташлар. Яшәү урыны буенча (кайда яшәүгә карамастан) рухташлар белән мәхәлләләргә берләшәсең.

Әлбәттә, илаһият юлында ошбу изге эшләрдә алгы рәттә дин әһелләре һәм руханилар барырга тиеш кебек. Әмма, тормыш күрсәткәнчә, алар Аллаһ юлында иҗтиһат кылырга әлегә бик ашкынып тормый. Чөнки илдәге сәяси системаның эчке тәртипләренә буйсынып яшәргә һәм шул кысаларда гына эш итәргә күнеккәннәр. Әмма бүген инде Җирдә илаһият кануннарына нигезләнгән яңа дөньяви тәртип урнаштыру вакыты җитте. Бу җәһәттән, хәтта күптән түгел кабул ителгән Россия тышкы сәясәтенең яңа концепциясендә дә Мәскәүнең, «универсаль вә традицион рухи-әхлакый кыйммәтләрне» саклауда халыкара тырышлыкны яклавы, дустанә ислам цивилизациясе белән дә гомумколачлы вә файдалы хезмәттәшлекне ныгытачагы турында әйтелә. Күрүебезчә, хәтта авызын бик чамалап кына ачарга күнеккән руханилар өчен дә бу юнәлештә, курыкмыйча, законлы итеп иҗтиһат кылу мөмкинлеге бар. Бу бигрәк тә мәхәлләләр һәм диния нәзарәтләре дәрәҗәсендәге эшчәнлекне, глобаль кризис сәбәпле туган яңа шартларга туры китереп, тәүхиди-иҗтиһади нигездә оештыруга кагыла. Моның өчен бары тик әзерлегең вә аң-белемең югары булу һәм иман ныклыгы гына кирәк.

Мондый шартларда инде аерым игътибарны мәгълүм вакыйгалардан соң хокукый кырдан ясалма төстә (сәяси максатларда) куылган татар милли хәрәкәтенә дә юнәлтәсе килә. Шок хәленнән чыгып, бәхетне һич читтән көтмичә, яңа шартларда яңабаштан һәм метасәяси (илаһият кануннары буенча яшәүгә күчүне максат иткән) нигездә төп эшкә алынырга вакыт. Моның өчен бүген бөтен мөмкинлекләр дә бар һәм халыкара хәлләр дә нәкъ шуңа этәрә. Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез өчен хәзер инде бу аеруча зур әһәмияткә ия. Шәхси планда аның механизмы бөтен татар дөньясы өчен дә уртак. Ә мәхәлләләргә берләшү һәм диния нәзарәте дәрәҗәсендә дә эшне башлау юлында инде төп йөкне, әзерлекле дин әһелләре белән бергә, һәр төбәкнең үзенә генә хас уңай вә тискәре якларын да исәпкә алып, милли хәрәкәткә (киң мәгънәдә) һәм милли-мәдәни оешмаларга да тартырга туры киләчәк. Иң мөһиме – андый эшчәнлек бүгенге кискен чорда төбәкләрдә төрле милләтләр вә диннәр арасында үзара аңлашу һәм татулыкны ныгытуга хезмәт итәчәк. Чөнки илаһият кануннары барлык халыклар вә диннәр өчен дә уртак.

Әлбәттә, татар милли хәрәкәтенең эшчәнлеге болар белән генә чикләнми. Яшәешнең төрле өлкәләренә кагылышлы һәм күпсанлы метасәяси проектлар булдыру һәм аларны гамәлгә кую, милли мәгарифне торгызу һәм яшь буынны ата-бабаларыбыз рухына тугры итеп тәрбия кылу мәсьәләләрен яңа шартларда хәл итү (ә төбәкләр өчен бу – аеруча мөһим), татар теленең кулланыш даирәсен киңәйтү һәм статусын күтәрү өчен ихтыяҗ вә шартлар булдыру, төбәкләрдә эшмәкәрлекне милли традицияләребезгә туры китереп җәелдерү аша, милли хәрәкәтнең матди вә финанс нигезен ныгыту кебек мәсьәләләр дә үз чишелешен көтә.

Фоат УРАЗАЙ.

Тукай хәзер нинди булыр иде?

Казанда «Алдынгылар хәрәкәте» балалар һәм яшьләр хәрәкәте бинасында оешманың җитәкчесе Тимур Сөләйманов инициативасы белән «Габдулла Тукай хәзер нинди булыр иде икән?» темасына дизайн эшләре – арт-сурәтләр, объектлар тәкъдим итүгә багышланган очрашу булды. Т.Сөләйманов, Клячкин хастаханәсендә Г.Тукай үлгән палатага яңа сулыш өрү максатыннан, яшь дизайнерлар ярдәме белән яңа иҗтимагый киңлек тудырылачагын әйткән иде.

Воркшоп-остаханәгә студентлардан барлыгы 46 гариза килгән, шуларның сигезе жюри әгъзаларына тәкъдим ителде. Алар арасында: «Тукай-Супермен», «Комикстагы Тукай», «Гарри Поттер Тукае», «Тукай экиятеннән бер күренеш» дип аталганнары бар иде. Өч кешене җиңүче дип игълан иттеләр.

Мария Анчугова өч ел ярым элек Татарстанга күченгән, кафелар челтәрендә каһвә пешерүче булып эшли. Ул «Алдынгылар хәрәкәте» бинасында каһвәханә ачарга ниятли. Аның рәсемендә касә тоткан Габдулла Тукай сурәтләнгән, касә эчендә – Су анасы, ә Тукайның бер җилкәсеннән Шүрәле карап тора. «Мин Тукайны яшь һәм заманча итеп сурәтләдем. Минемчә, аның татар яшьләренә карата фикерләре бүген дә үзгәрмәс иде. Шагыйрь образы яшьләр өчен кызыклы булыр дип уйлыйм. Рәсемнең үзенчәлеге шунда – аның фоны чын каһвә белән ясалды», – диде җиңүче Мария Анчугова.

Алёна Хәбибуллина фикеренчә, һәр кеше өчен Габдулла Тукай образы үзенчә күренә. «Кем өчендер Тукай – кәләпүшен киеп фотога төшкән шагыйрь, кем өчендер Габдулла Тукай диюгә аның вафатына берничә көн кала Клячкин шифаханәсендә төшкән фотолары күз алдына килә. Шуңа күрә мин шагыйрьнең төгәл рәсемен сурәтләмәскә булдым, аның исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме сүзләреннән силуэтын формалаштырдым», – диде ул.

Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты студенты Анна Савинова «Һәркемнең үз Тукае» дип имзаланган комикс тәкъдим итте.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

Гамьсез балачак сурәте

Китапның авторы кем, диган сорауга, әлбәттә, уйлап та тормыйча, язучы яки шагыйрь, йә булмаса галим, дип җавап бирәбез. Әмма рәссам китаплары да була икән. Ягъни мәсәлән, кылкаләм остасы җыентыкны башыннан ахырына кадәр үзе эшли. Дөрес, анда басылган текстның авторы булырга мөмкин. Шулай да бу очракта төп иҗатчы – барыбер рәссам. Шундый рәссам китабы күргәзмәсе Татар китабы йортында ачылды. Күренекле шагыйребез Роберт Миңнуллинның 75 еллыгына багышланган әлеге экспозициядә аның иҗатын үз эченә алган рәссам китаплары белән танышырга мөмкин.

Роберт Миңнуллин гомер буе Татарстан һәм Башкортстанны бердәй якын күрде, үзенең иҗаты белән ике республикада яшәүчеләрне якынайтырга, берләштерергә омтылды, шуңа күрә күргәзмәдә Татарстан һәм Башкортстан рәссамнарының берләшеп иҗат итүләре табигый. Биредә күренекле осталар – Салават Гыйләҗетдинов, Җәмил Әхмәтвәлиев, Дим Гобәйдуллин, Ирина Хлюпова, Юлия Абызова, Кама сәнгать һәм дизайн институты һәм Уфа сәнгать институты студентларының иҗат эшләрен күрергә була. Китап ул – кәгазьгә басылган хәреф һәм рәсемнәр генә түгел икән. Нинди генә җыентыклар юк күргәзмәдә! Тукымадан аппликация ысулында ясалганнары, урта гасырлардагы шикелле ханнарныкыдай мөһерләр сугылганнары, графиканың офорт, линогравюра техникаларында башкарылганнары... Хәтта корама юрганда шигырь юлларын укырга, озаклап рәсемнәр карарга мөмкин. Бөтен китапларны бер нәрсә – шагыйрьнең иҗатына хас туган як, балачак образлары берләштерә.

Сәнгать фәннәре докторы Рауза Солтанова Р.Миңнуллин иҗатының образлылыгын, аны рәсемләве җиңел булуын билгеләп үтте, рәссам китабы күргәзмәсенең сирәк, әмма гаять кызыклы чара икәнен ассызыклады, бу сәнгать төренең театр белән уртаклыгы барлыгына игътибар юнәлтте. Шагыйрьнең хатыны Клара

ханым Роберт Миңнуллинның гомер буе рәссамнар белән тыгыз аралашып яшәгәнен искә алды. Әдипнең энесе, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин Роберт аганың рәссамнар белән бергә шигырь китапларын бизәүдә катнашып, «Яшь ленинчы», «Сабантуй» редакцияләрендә эшләгәндә, меңләгән дәнә балалар газета-журналларын бизәп, үзенең дә чын мәгънәдә рәссамга әверелүен әйтте. Шуңа өстәп, Р.Миңнуллин фотоаппаратын кулыннан төшермәгән, дөньяга объектив аша карап, шулай ук сәнгати зәвыгын чарлаган. Иҗатындагы образлылык, сүз белән рәсем ясавы шуннан да киләдер.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

1 нче биттә – Белоруссиянең Вязьма каласында генерал М.Ефремов хөрмәтенә куелган һәйкәл. В. Имамов фотосы

Фронтовик-композиторлар күргәзмәсе

Татарстан Милли музеенда татар композитор-фронтовиклары – Фәрит Яруллин, Мәсгуть Латыйпов, Заһид Хәбибуллин, Рөстәм Яхин, Әнвәр Бакиров, Алмаз Монасыйповның шәхси әйберләреннән торган күргәзмә ачылды.

«Аерым экспозициядә композитор Фәрит Яруллинның фотоларын, хатларын күрә аласыз. Анда ул сугыш кырындагы хис-кичерешләрен чагылдыра. Шулай ук, үзенчәлекле документ та бар. Язмада 1941 елда композиторның «Шүрәле» балетын яңадан эшкәртә башлавы, әсәрне торгызуы турында сүз алып барыла. 1945 елның мартында әлеге балет Казан дәүләт опера һәм балет бинасында сәхнәләштерелә», – диде фәнни экспозицияләр бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре Миләүшә Хәйруллина.

Аның әйтүенчә, һәр композитор сугыш кырында ансамбль яки оркестрда җитәкчелек иткән. Музыка уен кораллары арасында иң киң таралганнары гармун, домбра, мандолина, скрипка була. Шушы уен коралларын да күрергә мөмкин.



Күргәзмәдә Мәсгуть Латыйпов, Заһид Хәбибуллин, Әнвәр Бакировның ноталары, әсбаплары, фотолары бар. «Сугышка киткән иң яшь татар композиторы – Алмаз Монасыйпов. Ул 18 яше тулу белән сугыш кырына китә. Сугыштан соң «Муса Җәлил» симфония-поэмасын, «Тукай аһәңнәре» вокаль-симфоник поэмасын иҗат итә. Экспозициядә композиторларның автографларын, пластинкаларын да күреп була», – диде Миләүшә Хәйруллина.

Татарстан Милли музеенда композитор Рөстәм Яхинның шәхси рояле тора. Күргәзмә ачылышында аның рояленда уйнап, сугыш чоры җырларын яңгыраттылар. Концерт программасы Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе студентлары чыгышлары белән дәвам итте.

Концертта төрле милләт вәкилләре татар һәм рус телләрендә Бөек Ватан сугышында популяр булган һәм сугышта катнашкан композиторларның әсәрләрен башкарды.

Күргәзмә 22 майга кадәр эшләячәк.

Зилә **МӨБӘРӘКШИНА**.

Заманча китапханә

Кукмара районының Олыяз авылында модельле китапханәләр төзү буенча республика программасы кысаларында үзгәртеп корылган китапханә ачылды. Биредә балалар, яшьләр һәм өлкәннәргә матур әдәбият һәм фәнни китаплар уку, ялны файдалы итеп уздыру өчен бар мөмкинлекләр дә тудырылган.

Тантанада район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Айгөл Әхмәтшина, «Урал» хуҗалыгы җитәкчесе Газинур Хәбибрахманов, Олыяз авыл җирлеге башлыгы Рамил Мәликов, Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни-методик бүлеге мөдире Люция Нәҗметдинова, республика яшүсмерләр китапханәсе директоры Наилә Вәлиуллина һәм башкалар катнашты.

Былтыр китапханә «2014-2025 елларда Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы нигезендә республикада модельле китапханәләр төзү буенча узган конкурста катнашып, җиңүче дип танылга һәм өч миллион сумлык грантка ия була.

«Мәдәният йортының икенче катында урнашкан китапханәдә хәзер һәркемгә: балалар, яшьләр һәм өлкәннәргә матур әдәбият һәм фәнни китаплар уку, ялны файдалы итеп уздыру өчен бар мөмкинлекләр дә тудырылган. Бик күп яңа җиһазлар, заманча җайланмалар, мультистудия, интерактив глобус, ламинатор, ике төрле принтер, вай-фай ярдәмендә эшли торган өйрәтү комплексы, 1800 данә яңа китап кайтты», – диде китапханә мөдире Сөмбел Камалиева.

Уңайлы әсбаплар

Татарстандагы балалар бакчаларын милли бизәлешле магнитлы такталар һәм карточкалар белән тәэмин иткәннәр.

Казанның Ершов урамында урнашкан 135 нче балалар бакчасында журналистларга Татарстан китап нәшрияты җитештергән яңа әсбапларны күрсәттеләр. Магнитлы карточкалар – мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләү әсбабы. Алар гаилә, азык-төлек, кием-салым кебек төрле темаларга багышланган. Магнитлы карточкалар ярдәмендә тәрбиячеләр балаларга уен форматында яңа сүзләр өйрәтә ала.

«Без балалар бакчалары өчен 800 магнитлы такта һәм 44 мең магнитлы карточка җитештердек. Алар Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан республиканың 800 бакчасына таратылды. Комплектка 1 такта белән 55 карточка керә. Киләчәктә төрле темага өстәмә карточкалар да җитештерергә була. Тактасын исәпләмәгәндә, алар кыйммәткә төшми. Тәкъдимнәр булса, китап нәшрияты яңаларын эшләргә әзер», – диде Татарстан китап нәшриятының генераль директоры Илдар Сәгъдәтшин.

Аның сүзләренчә, магнитлы такта һәм карточкаларны татар телен яки башка телне өйрәнгәндә генә түгел, ә тәрбия эшендә дә кулланырга мөмкин. Әсбаплар шулай ук сабыйларның уйлау сәләтен һәм вак моторикасын үстерү өчен дә файдалы.

135 нче балалар бакчасының татар теле тәрбиячесе Адилә Шәйхетдинова яңа әсбапларны уңай бәяләде. Алар ярдәмендә ул балаларга берничә дәрес биреп карарга өлгергән. «Магнит карточкалар белән эшләү үземә дә, балаларга да кызык. Алар үзләре такта янына килеп тотып карыйлар, ябыштыралар. Карточкаларның да, тактаның да зурлыгы ошый. Без аны махсус сабыйларның буе җитәрлек урынга куйдык. Биредә берничә бала берьюлы эшли ала. Тактага маркер белән язып та була», – диде тәрбияче.

135 нче балалар бакчасы мөдире Гүзәл Садыйкова сүзләренчә, 2018 елда ачылган бакчада бүген 465 бала тәрбияләнә. «17 төркемнең дүртесендә тәрбия татар телендә бара. Һәр параллельдә милли төркем бар. Аларга милли җанлы, татар телен камил белә торган татар тәрбиячеләрен куйдык», – диде мөдир.

Рифат **КАЮМОВ**.

Зиратларда хәтер өмәләре

Татарстан Язучылар берлеге әгъзалары һәм хезмәткәрләре Казанның Яңа Татар бистәсе зиратында хәтер өмәсе ясады.

Өмәдә Ркаил Зәйдулла, Марат Әмирханов, Газинур Морат, Рөстәм Галиуллин, Рафис Корбан, Ләбиб Лерон, Хәбир Ибраһим һәм башкалар катнашты.

Алар Габдулла Тукай, Әмирхан Еники, Атилла Расих, Илдар Юзеев, Әминә Бикчәнтәева, Нури Арслан, Фаил Шәфигуллин, Фәиз Зөлкарнәй һәм башка күренекле әдипләрнең каберләрен чистартты.

28 апрельдә Татарстан Диния нәзарәте һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе хезмәткәрләре дә Яңа бистә зиратында өмә уздырды.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм «Ислам кабул итүгә 1000 еллык» исемендәге мәдрәсә директоры Ильяс хәзрәт Зиһаншин җитәкчелегендә Татарстан Нәзарәте хезмәткәрләре һәм имамнары, мәдрәсә мөгаллимнәре һәм шәкертләре зиратның зур өлешен рәткә китерде, каберлекләрне чүп-чардан, кипкән үләннәрдән һәм корыган агачлардан аралады, аллеяларны себереп җыештырды, кабер ташларын чистартты. Ахырдан биредә җирләнгән дин әһелләренең, күренекле мәгърифәтчеләрнең, остазларның рухларына күмәкләп дога кылынды.

Җиһан шаһит

● Forbes журналы Мәскәүне миллиардерлар иң күп яшәгән шәһәрләрнең беренче унлыгына керткән – биредә 61 бай эшкуар теркәлгән. Беренче урынга куелган Нью-Йоркта 101, Гонконгта – 70, Пекинда – 68, Шанхайда – 65, Лондонда исә 63 миллиардер яши. Алтынчы урындагы Мәскәүдә яшәүче акча капчыкларының гомуми мөлкәте 307 миллиард долларга тәңгәл, бу былтыргыдан 92 миллиард долларга күбрәк. Россиядәге чынбарлык бер дә гаҗәпләндерүдән туктамый – Көнбатыш чикләүләренә, илдә махсус хәрби операция баруга, чит илләрдәге активларга арест салынуга, сум зәгыйфьләнүгә, социаль чыгымнарның кимүенә, илдәге икътисадый вәзгыятьнең катлаулануына һәм россиялеләрнең тулаем хәерчеләнүенә карамастан, Мәскәү миллиардерларының өчтән ике өлеше үз байлыгын тагын да арттыруга ирешкән.

● «Калфак туе»нда «Ак калфак» укучы кызлар бәйгесенә йомгак ясалды. Конкурсның Гран-при иясе Чуаштанның уңган кызы Рүзилә Хәмдиеваны котлау мизгеле.

● Илмира Галимова «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнде.

МИЛЛӘТ ТЕЛСЕЗ БУЛА АЛМЫЙ

Казанда өч көн дәвамында III Бөтендөнья татар хатын-кызлары съезды узды. Аны Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты «Ак калфак» татар хатын-кызлары оешмасы белән берлектә оештырды. Съездда Татарстан районнарыннан, Россия төбәкләреннән, 15 ерак һәм якын чит илдән 500 дән артык делегат катнашты.

«Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә делегатларны, кунакларны фольклор ансамбльләр җыр-бию белән каршы алды. Килүчеләр исә иң әүвәл кул эшләре – милли аксессуарлар күргәзмә-ярминкәсе белән таныштты. Ә анда чигүле түбәтәйләр, калфаклар, яулыклар, изүләр, сумкалар – һәркайсы күз явын алырлык матур. Күңелгә ошаганын сатып та алырга мөмкин.

Пленар утырыш Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыевның сәламләве белән ачылды. «Татар хатын-кызы тыраыш, булдыклы, сез тормышның барлык өлкәләрендә – икътисадта, мәгарифтә, фәндә, мәдәниятта, эшмәкәрлектә, хакимият һәм җирле үзидарә органнарында хезмәт куясыз. Сез – татар гаиләсенең йөрәге. Сез булганга, татар дөньясы яши», – диде ул.

Аннары Милли Шура җитәкчесе Республика Рәисе Рөстәм Миңнехановның съезд делегатларын котлавын ирештерде.

Бөтендөнья татар хатын-кызлары хәрәкәтенең координацион Советы рәисе, «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасы җитәкчесе Кадрия Идрисова соңгы дүрт елда башкарылган эшчәнлеккә хисап ясаган чыгышын Исмәгыйль Гаспралының хатын-кызларга өндәмәсен җиткерүдән башлады. Ул хатын-кызларыбызның дөньяга ана булу миссиясе белән килүләрен, милләткә яраклы ул-кызлар үстерергә тиешлеге безне искәртә, балаларыбызның телне, үткәннәребезне һәм гореф-гадәтләребезне саклаучылар булып үсеп җитешүе мәслихәт икәнлеген әйтә. Милли тәрбия ана сөте белән керергә тиеш. «Татар рухы кече яшьтән үк җаныбызга сеңдерелгән булса, без аны беркайчан да югалтмабыз. Милли мәдәниятебез һәм сәнгатебез, йолаларыбыз, гореф-гадәтләр яшәешебезнең умыртка баганасы булып тора. Без аларны киләчәк буынга, балаларыбызга тапшыра алдыкмы?» – дип залга сорау белән мөрәҗәгать итте ул. Бөек галимебез Ш.Мәрҗани дә «Өч әйбер диндә юк, әмма алар динне саклый: милли тел, милли кием һәм милли гореф-гадәт», дип язып калдырган. Бу – оешма эшчәнлегенең нигезе. Күчмә утырышларда әлеге мәсьәләләр һәрвакыт катгый күтәрелә. Балаларыбыз, яшүсмерләребезнең милли үзаңын уяту, гаилә учагын тергезеп, милләт яшәешенә ут өстәп тору – беренче чиратта хатын-кыз бурычы. «Татар рухы кече яшьтән ук җаныбызга сеңдерелгән булса, без аны беркайчан да югалтмыйбыз. Гаиләдәге тәрбиягә, әхлакый канунnarны нәкъ менә гаиләдә саклауга аеруча игътибар бирергә тиешбез», – диде К.Идрисова. «Ак калфак» җитәкчесе әлеге максатка ирешү юнәлешендә үткәрелгән җыеннар, күчмә утырышлар, киңәшмәләр, конференцияләр, «Каз өмәсе», укучы балалар бәйгеләрен, «Татар малае», «Татар кызчыгы» конкурсларын искә төшереп үтте. Узган ел соңгы конкурста гына да 31 мең бала катнашкан. Быел инде «Татар малае», «Татар кызчыгы»нда катнашучылар саны 32 меңгә якынлашып килә. Бу инде шуның кадәр ул-кызыбыз телебезне, үз шәҗәрәсен, гореф-гадәтләребезне тиешенчә өйрәнгән, дигән сүз. «Мәдәни җомга» газетасында утырышлар һәм җыеннарның күбесе яктыртылып барды.

Кызганыч ки, соңгы елларда татар мәгариф системасы гаять зур югалтуларга дучар булды, күп төбәкләрдә татар теле һәм әдәбияты дәресләре бөтенләй юкка чыкты. Ләкин сабый, ике-өч яше тулуга, киң дөньяга юл ала, балалар бакчасы, аннары мәктәпкә китә, ә анда – бүтән төрле тәрбия системасы, башка менталитет. Татар хатын-кызлары оешмасы җитәкчесе әлеге хәлдән чыгу юлын шәхси милли мәктәпләр ачуда күрә. «Безгә каяндыр, нindидер ярдәм көтеп утыру – кирәкмәс шөгыль. Алда шәхси милли балалар бакчалары, мәктәпләр ачу бурычы тора. Милләтебезгә креатив шәхесләр кирәк! Аларны бары тик милли үзаңы булган татар аналары гына тудыра һәм тәрбияли ала. Шәхси мәктәп ачу теләге белдерүчеләр дә бар. Бу хакта Төмән һәм Оренбург өлкәләре сүз алып бара», – диде ул.

Татарстан Дәүләт Советы депутаты, автоном коммерциягә булмаган «Бала-Сити» гомуми белем бирү оешмасы генераль директоры Альбина Насыйрова шәхси мәктәп булдыру юнәлешендә алып барылган эшләре белән таныштырды. Ул үзе өч бала анасы. «Әле тагын меңнән артык балам бар. Алар безнең балалар бакчалары һәм мәктәпләрдә тәрбияләнә. Казаныбызда 5 балалар бакчасы һәм 2 мәктәбебез эшли. Беренче улым тугач, ун ел элек, туган телне саклап, милли рухны тәрбияләп һәм шул ук вакытта башка чит телләрне дә яхшы белсен өчен, шушы таләпләргә туры килерлек балалар бакчасын ачып җибәрергә булдым», – ди ул. «Бала-Сити» уку йортында балалар ике яшьтән алып дүрт тел мохитендә тәрбия, белем ала. Барлык балалар да татар телен өйрәнә. «Тукай теле», «Татар теле» атналыклары, Сабантуйлар, күренекле шәхесләр белән очрашулар һ.б. даими үткәрелә. «Бала-Сити» бүгенге көндә татар теленә кызыксыну уяту, аны кызыктыргыч һәм мавыктыргыч итү ниятеннән, «Акыллы уеннар» проектын тәкъдим итә. Ун төрле өстәл уены уйлап тапканнар. Алар татар телендә генә алып барыла. Балалар бу дәресләргә бик яратып йөри. «Республика Рәисе дә бу проектны хуплады. Татарстанның 100 муниципаль балалар бакчасы шушы проектны кертәчәк», – ди Альбина ханым.

«Акыллы әкиятләр» – шулай ук кызыклы проектның берсе. Махсус язылган, замана балаларына кызыклы булырлык әкиятләрнең һәрберсе сорау белән тәмамлана. Аларга балалар үзләре җавап таба. Аннары «Бала-Сити» шәһәрнең үзәгендә Сабантуй уздыруны да гадәт иткән. Анда төрле милләт балалары барысы да татарча җырлый, бии, бәйгеләрдә катнаша. Гомуми белем бирү оешмасының тагын бер проекты – «Туган тел» фестивале. Алар аны мәгариф министрлыгы һәм Татарстан Рәисе каршындагы телләрне саклау-үстерү комиссиясе белән берлектә оештыра. Ул республикада яшәүче актив, креатив методистлар, татар теле укытучылары, тәрбиячеләр белән берлектә уздырыла. «Татар теле клубы» – саф татарча сөйләшә белми торган замана әтиәниләре өчен. Актив ата-аналар биредә татар телен өйрәнә. Делегатлар һәм кунаклар «Бала-Сити» мәктәбенә барып бу күркәм эшләр белән танышып та кайтты.

Башкортстан татар хатын-кызларының «Ак калфак» берләшмәсе җитәкчесе, иганәче Люция Вафина күңелендә үз халкына, аның мәдәниятенә, гореф-гадәтләренә мәхәббәте, киләчәк буыннарга тапшыру теләге шулкадәр көчле була ки, аның милли хисләре, киртәләргә карамастан, эшчәнлегендә барыбер үз юлын таба. Ул эшчәнлек үзе оештырган ике коллективтан башланган, татар гореф-гадәтләрен саклый торган фольклор ансамбльләренең исәбе инде 56 га җиткән. Алар «Ак калфак» оешмасының балалар, мәктәпләр белән бергәләп үткәргән бәйрәмнәрендә, кичәләрдә катнаша, милли җыр-биюләребез һәркемнең дә күңеленә хуш килә.

(Дәвамы 15 нче биттә).

● Хезмәтенә күрә хөрмәте.

Бөек Ватан сугышы тарихы белән әз-мәз таныш кеше дә Георгий Константинович Жуковның кем икәнен беләдер дип уйлыйм. Сугышның Мәскәү оборонасы, Сталинград, Курск дугасы, Днепр елгасын кичү, фашистларның башкаласы Берлинны алу кебек иң җаваплы операцияләргә нәкъ менә маршал Жуков җитәкчелек итә. Күпме корбаннар булачагын гадәттә ул исәпләп тормый. Аның өчен бары бер нәрсә генә мөһим була – җиңү! Ил башлыгы Сталин да аннан җиңү таләп итә.

АЯУСЫЗ МАРШАЛ

Г.Жуков Калуга губернасының Стрелковка авылында хәерче крестьян гаиләсендә туа. Георгий әнисе Устиния Артемьевнаны, авылның бик куәтле кешесе кызын горурланып искә ала. Ул да әтисе кебек үк көчле шәхес була. Георгий бабасы Артем атны койрыгыннан тотып, аны җиргә утырта алган. Георгийның әтисе Константин ятим үсә, өч айлык чакта аны приютка бирәләр. Константин балалар йортында тәрбияләнә. Күрәсең, Георгийның булачак әтисенең тормышы рәтле-башлы килеп чыкмый, ул хатыныннан аерыла. 41 яшендә Константин кабат өйләнә, 26 яшьлек Устиния дә инде беренче иреннән аерылып кайткан була.

Яңа оешкан гаилә Устиниянең әнисе йортында Стрелковка авылында яши. Ике тәрәзәле бер бүлмә. Стеналар һәм түшәме мүкләнеп беткән, өйнең почмагы кыегайган. Аларның бер-бер артлы өч балалары туа. Олы кызлары Маша, икенче балалары – Георгий. Кече уллары бары бер ел гына яши, үлеп китә.

Георгий әти-әнисен бик ярата. Дөрес, алар таләпчән була. Әгәр нәрсә дә булса ошамаса, әтисе каеш белән «кыздырып» алырга да күп сорап тормый, әмма Георгий да гафу үтенергә яратмый, холкын күрсәтә...

Бервакыт шулай, әтисе яхшы гына кыйнаганнан соң, Георгий өйдән чыгып кача, якындагы киндер басуына яшеренә. Аның кайда булуын бары апасы гына белә, ул энесенә ашарга китереп йөри... Әмма бер көнне Георгийны күрше хатыны күреп ала һәм өйләренә кайтара. Билгеле инде, әтиләре моның үчен ала. Дөрес, бераздан улын гафу итә.

* * *

Георгий яшьтән үк куркусыз булып үсә. Уналтынчы яше белән барганда, янгын чыккан йорттан тавышлар ишетеп, ул тәрәзәдән кешеләрне коткарырга ташлана. Йорт эченнән авыру карчыкны һәм куркынган балаларны алып чыга. Соңрак, Мәскәүдә тегү остаханәсендә өйрәнчек булып эшли башлагач, үзен мәсхәрәләүчеләрне акылга утыртырга да күп сорап тормый. Өйрәнчеклек вакыты төгәлләнгәндә, үзен хурлаган приказчикның башына таяк белән тондыра, ә анысы аңын югалтып идәнгә барып төшә. Бу вакыйгадан соң хезмәттәшләре аңа әтисенең исемен дә кушып «Георгий Константинович» дип дәшә башлыйлар.

1915 елның августында хәрби хезмәткә чакырылгач, Жуков офицерлар училищесына барырга хокукы булса да, рядовой солдат булып хезмәт итәргә керешә. Күрәсең, хәрби эшнең нечкәлекләрен аңламаган көйгә, яшьләре буенча үзенә әти булырлык солдатларга командалык итәргә теләми.

Жуков хезмәт итү чорында үзенең кискен характерын еш күрсәтә. Инде дивизия белән җитәкчелек иткәндә, ул Белоруссия хәрби округы башлыгы Уборевичтан шелтә алгач, җитәкчесенә шундый телеграмма җибәрә: «Сез хәрби округның чамадан тыш гаделсез җитәкчесе. Мин сезнең белән бергә хезмәт итәргә теләмим. Мине теләсә нинди башка округка җибәрүегезне сорыйм.» Уборевич яңадан тикшереп, шелтәне юкка чыгара, Жуковны тынычлыкта калдыра. Аның дивизиясе армиянең иң яхшысына әверелә.

Тагын бер шундый хәл турында да сөйлиләр. Ул хакта маршалның кызы Мария язып чыга: «Ниндидер бер тантаналы кичәдә кызмача өлкән яшьтәге большевик Ермаков Жуковка үзенең патша гаиләсен атып үтерүдә катнашуы турында сөйли, аның тәбрикләвенә өметләнеп кулын суза. Жуков сораулар бирер, котлар дип өметләнә. Ә маршал үзен башкача тота. «Мин палачка кул бирмим», – ди.

* * *

1941 елның 14 июнендә оборона халык комиссары Тимошенко һәм генштаб башлыгы Жуков Сталинга чик буе округлары гаскәрләрен генә булса да хәрби әзерлек хәленә китерү зарурлыгы турында белдерә. «Бу сугыш дигән сүз була бит», – ди Сталин. Һәм Тимошенко белән Жуковка кискен карашын юнәлтә. Аннары Жуков белән янәшә басып, болай ди: «Нәрсә, сезгә званиеләр һәм орденнарыгыз җитмиме? Сугышырга тели башладыгызмы?» Аннары ишеген шапылдатып ябып, бүлмәсеннән чыгып китә.

Бервакыт Рокоссовский Жуковның Баш командующий белән аралашуын күзәтеп тора: «Сталин үзенең кәефе китүен, калтырануын яшерми. Ниһаять, Сталин: «Сез ирекле, бар, китегез, уйлагыз, иптәш Жуков», – ди. Бүлмәдән чыкканда, Рокоссовский юлбашчы белән алай сөйләшергә ярамавын әйтә. «Без кайчак болай гына сөйләшмибез әле», – ди Жуков. Бервакыт, югары постлар биләүче хәрбиләр белән сөйләшкәндә, Баш командующий үзе дә бу фикерне кабатлый. «Сез барыгыз да, мин нәрсә генә әйтсәм дә, әйе, иптәш Сталин, әлбәттә, иптәш Сталин, сез бик акыллы карар кабул иттегез дип җөпләп торасыз. Бары бер кеше генә кайвакыт минем белән бәхәскә керә. Ул – Жуков».

Беренчесен – Көнбатыш фронт җитәкчесе, икенчесен аның урынбасары итеп раслагач, Сталин Жуков белән Коневка: «Әгәр Мәскәүне фашистлар алса, икегез дә башыгыз белән җавап бирәчәксез», – ди.

Бу вакытта инде немецлар, шушы көннәрдә Мәскәүне алачакбыз дип, Кызыл мәйданда җиңү маршы үткәрү репетицияләрен ясый башлаган булганнар. Ә совет гаскәрләрендә югалтуларны санап бетерә алмыйлар. Мәскәүгә омтылучы фашистларны туктату бик авырлык белән бирелә. Һәркемнән чигенмәве, дошманны уздырмавы таләп ителә. Приказны үтәгәндә, бик күпләр яу кырында ятып кала.

Тәртип урнаштыру өчен, Жуков иң кискен чараларны куллана, куркакларны гаскәр алдында хәтта атып та үтерә. «Уңышны кеше ите китерә дип уйламагыз, аны сугыш сәнгатен оста үткәрү нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин», – дип кабатларга ярата ул.

«Маршал Жуков. Человек, который победил Гитлера» китабы авторы Альберт Акселл: «Бу сугышны стратег Жуковмы, әллә бүреген ыргытып эш итү принцибын кулланучы Жуков оттымы?», – дип сорагач, ул: «Бу сугыш кан коюга көйләнгән иде. Чөнки Гитлер башта ук юлда очраган һәрнәрсәне дә җимерергә, һәр дошманны үтерергә әмер бирде. Шунлыктан берәүне дә үтермәгез, догалар гына укыгыз дип пропагандалаган чиркәү хезмәткәрен хәрби җитәкче итеп куеп булмый иде. Үлем күп булды. Зур югалтуларсыз Гитлерны туктату мөмкин булмавын сугыш үзе раслады», – дип җавап бирә.

* * *

1945 елның 15 мартында Гитлерның Берлин оборонасы комиссары Геббельс көндәлегенә шундый сүзләрне язып куя: «Ничек кенә яхшы әзерләнмәсен, безнең соңгы вакыттагы бер генә операция дә уңыш китермәде, барысы да көлгә әйләнде. Сталинның совет маршалларын кино йолдызлары кебек тәбрикләргә тулы хокукы бар».

16 мартта Геббельска совет генералларының, маршалларының бөтен нечкәлекләре белән язылган характеристикалары һәм биографияләре тупланган китапны бирәләр. Алар белән танышкач, Геббельс көндәлегендә шундый язма барлыкка килә: «Мин китап турында фюрерга хәбәр иттем. Без, гомумән, андый җитәкчеләргә көндәшлеккә керә алмыйбыз дип өстәдем. Фюрер минем фикер белән тулысынча килеште».

Геббельс ни өчендер бу вакытта иң хәлиткеч юнәлешләрдә хәрәкәт итүче маршал Жуков фоторәсемен карап утыруы турында телгә алмый. Моны белгәннән соң, маршал «минем фотоны каян тапканнардыр, ул хәтта минем үземдә дә юк», – дип гаҗәпләнә.

Жуковның маршал Васильевский белән бергәләп Сталинград янында, Курск дугасында вермахтны тар-мар итү планнарын эшләве, Висла–Одер операциясен сокланырлык итеп оештыруы мәгълүм. «Рим империясе таркалгач, мондый хәлне Европаның күргәне булмады, – дип яза соңрак немец генералы Меллентин. – Берлинның, шулай ук Геббельсның үзенең дә язмышы нәкъ менә шушы кешегә бәйле булды.

Котылу мөмкинлеге калмавын Геббельс та яхшы аңлый.

* * *

Маршалның бөтен тормыш юлы риваятькә ошаган. Патша армиясендә хезмәт иткәннән соң, ул ничектер концлагерьга эләкми калган, ике тапкыр Георгий тәресе алган, берничә тапкыр яраланган, контузия алган, бер колагы ишетми башлаган, тиф белән авырган, тик маршалга кадәр күтәрелгән. Сталинга да кычкырырга гадәтләнгән кешене ничектер яшерен рәвештә берәр йорт ишегалдында үтереп ташламаганнар. Сугыштан соң күпме шикаятьләр язылса да, Жуков исән калган. Сталин үлгәннән соң да, һәркем аның белән исәпләшкән.

Гади халык та Георгий Константиновичны төрлечә бәяләгән. Кайберәүләр коткаручы дип аңа табынган, икенчеләре «канэчкеч» дип атаган.

Жуковның кызы Мария бер китапта әтисенең Аллага ышанганмы-юкмы икәнлеге турында мәгълүмат булмавына гаҗәпләнүен белдерә, аның динне хөрмәт итүен раслый. Киевта маршал фашистлардан азат иткән гаҗәеп Гербовец изге ана иконасы сакланган. Жуковның фронтларда Казан изге ана иконасын йөртүе дә мәгълүм. Күптән түгел моны архимандрит Иоанн (Крестьянкин) да раслый. Бервакыт маршал Брест өлкәсенең Омелец руханиеннән хат ала. Ул илбасарларның барлык чиркәү чаңнарын алып китүләреннән зарлана. «Бик тиздән маршалдан бер тонна авырлыктагы посылка килеп төшә. Анда өч чаң салынган була, – дип яза Мария. – Чаңнар бүген дә чиркәүләрдә эленеп тора. Маршалның хаты да саклана».

«Мин тиздән үләрмен, теге дөньядан сине күзәтеп торырмын, авыр хәлдә калган минутларында яныңа килермен», – дип яза әтисе 16 яшьлек Машага. Күптән түгел Мария Георгиевна бу хакта белдерә (күрәсең элегрәк бу сүзләр сәер тоелгандыр). Мөгаен, әтисе кеше рухы мәңгелек дип санаган, дингә чын күңеленнән табынган булгандыр.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ.

Үз шигырьләрен яттан белгән шагыйрьләргә мин сокланып, хәтта көнләшеп карыйм... Уңае чыкканда мин дә үз шигырьләремнең, поэмаларымның кайбер строфаларын искә төшерәм һәм сүз арасына кыстырып җибәрәм. Шуларның кайберләрен сезнең игътибарга да тәкъдим итәм.



Ренат ХАРИС

Татар җыры - ерак дәверләрнең безнең телдә әйткән сәламе...

(Уңае чыкканда)

* * *

Шагыйрьсез халык ил түгел,
шигырьсыз акыл – чирле.
Җир шары да хисле җисем
шагыйрь туганнан бирле!

* * *

Шагыйрь ни генә язса да,
яза зурлап милләтен!
Шунда һәр милли әсәрнең
халыкара кыйммәте.

* * *

Ә бит шагыйрь булып була,
иң-иң- иң ким дигәндә,
Телең – Ана,
үзең – Бала
булып сөтен имгәндә!

* * *

Татар тарихының тәмен –
тозын, балын, борычын –
белгән кеше генә үти
олы милли бурычны...

* * *

Уйламасаң, яшәү рәхәт!
Уйласаң, башың катар –
авыз эчендә яшибез!
Шуны онытма, татар!

* * *

Күңел ул кешедән зуррак,
зуррак Җир шарыннан да:
анда – йолдызлар, чиксезлек,
киләчәк, үткән – анда;
анда дөньялар ярала,
яши һәм китә үлеп...
Күңел – Аллаһы ук түгел,
Аллаһ – кеше күңеле!

* * *

Көчсез буласың киләдер...
Аңлыймын ла, аңлыймын:
ә хатын-кыз беркайчан да
көчсез була алмый ул...

* * *

Татарча җырлап аш пешер
һәм ипи кис телемләп –
кухня теле кадерлерәк
парламентлар теленнән!
Бабаңның татар булуы
синең казаныш түгел.
Оныкларың татар булып
яшәве кирәк бүген...

* * *

Татар иле Татарстан,
син яңадан калыктың.
Син – рухы, көче, намусы
татар дигән халыкның...

* * *

Сабантуйларның саны юк,
юк Сабантуйның яше...
Сабантуй һәрбер татарның
йөрәк түрендә яши.

* * *

Шагыйрь патша булмый, имеш...
Бик буласы... Бик тели...
Аллаһ буласы килгәнгә
патша буласы килми...

* * *

Ватан тарихына үз исемен
җаны белән язган башкалам.
Россиянең бөек җиңүләре
Казан исеме белән башланган.

* * *

Хатын елый йөрәк белән,
ир елый акыл белән...
Ирләрләр елаган чагында,
аларга якын килмә...

* * *

Ил белән идарә итү
халыктан курка-курка,
Россия сәясәтендә
мәңге йөзүче турта...

* * *

Ялагайлана алмадым –
горурлык Алыпныкы,
акылым үземнеке һәм
йөрәгем халыкныкы.

* * *

Яраклашмадым халыкка,
чөнки мөмкин түгел эш,
чөнки меңне сыйдыралмый
меңнән алган бер өлеш.

* * *

Туган телемнән башлана
туган илем минем өчен.
Туган телем – минем рухым,
туган телем – минем көчем.
Туган илемнең исеме
туган телем исеменнән!
Алар бер булудан туа
горурлану хисе миндә!

* * *

Алгарышка йөз тотканга күрә,
сүз байлыгын без дә арттырдык –
урыс телен татар тегермәне
ташларына салып тарттырдык.

* * *

Яшисе килә кешечә –
бернидән дә шикләнмичә,
беркемнән дә курыкмыйча,
яшәү ямен эч-эчә.

* * *

Сырты атның әзерияр –
озын, хәтәр юллар башы...
Сул кул тезгенгә ябышкач,
уң кул кылыч сорый башлый...

* * *

Татар татар инде һәрчак –
гаҗәп эшләр майтара:
дошманы итеп куа да,
патша итеп кайтара...

* * *

Мәхәббәт ул ләззәт – бәхәсләшмим.
Мәхәббәт ул газап – килешмим,
мәхәббәт ул Җәннәт багларының
тәмуг уты янган өлеше...

* * *

Көз гөлләре чәчәк аткан саен
яз яңадан кайта күңелгә.
Иң кадерле истәлекләр булып
чәчәкләрдән чыклар түгелә...

* * *

Безнең барлык кылганнарны
тарих торадыр барлап...
Каеннар санын арттырдык
имәннәрне акшарлап...
Һәм берзаман яңгыр яуды,
юды барлык буяуны...
Иван булып йөргән татар
Имам булып уянды...

* * *

Гаҗәеп ачыш ясадым...
Кинәттән... Бер дә юктан...
Тукай сүзендә йакут бар,
йакут сүзендә – Тукай!

* * *

Татар телле маңкортлар бар,
башка телле асыллар –
тел ул сүздә генә түгел,
тел ул – җан кыйбласында!

* * *

Казан евро-азиялек
мәркәзенә әйләнде:
Европадан – яшеренлек,
Азиядән – хәйләлек.

* * *

Рифмага ияреп, фикер,
челтәрләр үрә-үрә,
ир куйнына кергән кыздай,
хис кочагына керә...

* * *

Табучы белән багучы
бер үк хатын булсачы!
Икесе ике булганда
бала язмышы ачы...

* * *

Тапканы түгел, бакканы,
көләргә өйрәткәне,
теле түгел, җаны белән
«Балам!» диеп әйткәне,
үз гадәтен сеңдергәне,
иңдергәне үз аңын,
күкрәк сөте бирмәсә дә,
чыны була ананың!

* * *

Бөек җырчыларсыз халык булмый.
Татарның да озын язмышын
бизәгәндер төрле дәверләрдә
даһи җырчылары тавышы.

* * *

Тел белмәүче бүген шигырь яза,
нота танымаучы көй яза,
тавышсызлар шуны мөгериләр –
ә бу инде Җырга җеназа...

* * *

Табигатькә һич хас юкса
әдәп-әдәпсезлек камыты...
Үзе уйлап тапкан кануннардан
кеше үзе яши кан йотып...

* * *

Хисләрендә акыл балкып торса,
шагыйрь көчле, шагыйрь бик зирәк.
Яшәр өчен куәт өсти торган
сүзе бетсә, шагыйрь җан бирә.

* * *

Беләсезме, татар җырларында
бөтен нәрсәсе бар Галәмнең!
Татар җыры – ерак дәверләрнең
безнең телдә әйткән сәламе.

* * *

Татар җырындагы хатын-кызлар
Ай, йолдыздан Җиргә күчкәннәр,
бер күрүдә онытылмас өчен
сагындыру суы эчкәннәр.

* * *

Көрәшкәннәр, атта узышканнар,
үрләгәннәр шома колгага
Сабантуйларында җиңүчегә
корал бүләк итү булмаган.

* * *

Куркаклык һәм Курку бердәй түгел,
мәгънәләре урап бәйләнгән.
Ә үлемнән курыкмаган кеше
Үлем мишененә әйләнә.

* * *

Татар аты Җирдә бетәчәкме?
Бетмәячәк! Тамчы кайгырмыйм,
күрәмен дә кайчак биш аяклап
бия куып йөргән айгырны.

* * *

Нигә татар шундый саксыз икән –
тарихының белми кадерен...
Халык бит ул халык булып яши
озын булса гына хәтере...

* * *

Читеккә бизәк кирәктер –
ул намазлыкка баса,
ә намазлык җәннәт багын
якынайта лабаса!..
Безнең акыллы элгәрләр,
җир рәнҗемәсен диеп,
хәтта сабанга чыкканар
чигүле итек киеп...

* * *

Килешми безгә хәреф һәм
сүз югалтуны аклау –
сүзне саклаудан башлана
телне һәм илне саклау!

* * *

Әти яулап алган бөек Җиңү
бәйрәм булып яши йөрәктә.
Ә кешене бәйрәм чын кешечә
яшәү һөнәренә өйрәтә.

* * *

Кеше бәхеткә дип туа!
Ә Бәхет ишегенә
сау-сәламәт барып җитә
рәхмәтле кеше генә!

* * *

Кереп барам якты көнгә...
Ә дөньяда болын исе!
Болын исле Җир шарында
мең яшисе, мең яшисе!

ЛЕГЕНДАР «КАТЮША»ЛАР КОМАНДИРЫ

Бөек Ватан сугышы каһарманы Барый Габдулла улы Йосыпов 1903 елның 10 декабрендә Самара губернасының Бөгелмә өязендәге Әлмәт авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә.

Барыйның әтисе Габдулла 1914 елда вафат була. Шуннан соң ир бала әнисе Фатыймага зур таяныч булып, аңа бар эштә дә булышлык итә башлый. Иртә таңнан алып кичкә кадәр кырда эшли. Аның дәү әтисе Йосыфны авыл халкы зур иген уңышына ия, өстәвенә 40 баш умарта корты да тоткан тырыш зат буларак искә ала. Әмма бу гаиләнең матди хәле көннән-көн начарлана гына бара. Гаиләдә – дүрт бала: Барый, апасы Нурлыбанат һәм энеләре Гадрахман һәм Габделәхәт. Ни кызганыч, апасы, укытучы тиф белән чирләп, яшьли китеп бара.

Барый үсеп җитәм дә, игенче булам дип хыяллана. Әүвәл мәдрәсәдә укый. Әмма җитди белем алу аның өчен бары тик инкыйлабтан соң гына мөмкин була. Ул бу хакта һәрчак искәртә киләчәк. Геройның 1965 елда язган автобиографиясендә: «Үз тормышымның иң күп өлешен илебездәге совет властен тулысынча ныгытуга багышладым», дигән юллар да бар. Аңа кулакларны фаш итүдә дә катнашырга туры килә, гражданнар сугышы елларында ак гвардиячеләр кулыннан зыян күреп, алар тарафыннан кыйнала да. 1919 елда комсомол оешмасы сафына керә. 19 яшендә 16 нчы Мөселман командирлык мәктәбе курсантына әверелә. 1922 елның май-сентябрь айларында, курслары белән бергәләп, Урта Азиядәге басмачлар хәрәкәтен тар-мар итүдә дә катнаша. Кушкада бик нык эссе, яңгырның әсәре дә юк. Мондый эсседән бер курсант вафат була, берничәсе госпитальгә эләгә. Тропик малярия эпидемиясе котыра, малярия бизгәге аны да урап узмый. Госпитальдән кире казармага чыгаралар, яшәрлек көч-куәте кими бара. 22 көн казармада яткан егеткә дусты Сабит булыша. Ниһаять, Барый терелә. Аннан кайткач, Казандагы курслар да тәмамлана. 1924 ел. Менә ул инде – кызыл командир! Шуннан соң егет Томск каласына юнәлеп, анда бүлек командиры, рота агитаторы булып хезмәт итә. Тиздән пулемётчылар взводы командиры вазыйфаларына керешә. Уфага сугылган көннәрдә булачак җәмәгате Һаҗәр белән танышып, аның белән хатлар алыша башлый. Кыз Томскига килеп, балалар йортына тәрбияче булып урнаша. Гаилә коргач, 1926 елда уллары Нариман туа. 1927-1928 елларда Красноярскидагы артиллерия мәктәбендәге укулардан соң Барый Габдулла улын Уфа артиллерия мәктәбенә ут взводы командиры итеп билгелиләр.

Тормыштагы очрашуларның тарихи әһәмияткә ияләре дә була. Калуга янәшәсендәге ял йортына баргач, ул санаторий янәшәсендәге урманда һава сулап йөрүче К.Э.Циолковский белән таныша. Әңгәмә башында аның татар милләтеннән икәнен белгәч, Циолковский аңа: «Минем әнием, кыз чагында – Юмашева, әтисенең нәсел жебе буенча татар бит», – ди. Шул көнне әлеге галим «Космические ракетные поезда», «Общечеловеская азбука», «Растения будущего» дип аталган өч брошюрага култамга язып, аларны киләчәктә каһарман булып танылачак татар инсанына бүләк итә.

1930-1934 елларда Б.Йосыпов Ленинградтагы Ф.Э.Дзержинский исемендәге Хәрби-техник академиядә укый, «Артиллерийский журнал» дип аталган басмада аның мәкаләләре дә дөнья күрә. Укуны тәмамлагач, Барыйны Ташкенттагы хәрби мәктәпкә юллыйлар. Ул анда әллә ни озак укытмый. Эш буенча Мәскәүгә барган Йосыпның йөрәге авырта башлый, табиб аның малярия белән авырганын белгәч тә, санидарәгә рәсми кәгазь юллый: бу хәрби кеше илнең урта полосасында гына хезмәт итә ала. Йосыповны Рязаньдагы артиллерия училищесына өлкән укытучы итеп билгелиләр. Хәрби булып китүенә үкенми

● Б.Йосыповның әнисе Фатыйма Йосыпова.

● 1930 ел.

ул, чоры шундый, тынгысыз ич... Ләкин ил тормышы тагы да тискәрерәк якка үзгәрә, менә инде Советлар Союзы маршалы М.Тухачевскийны да төрмәгә тыкканнар... Бу хакта аңа Куйбышевтан күчерелгән бер хәрби әйтеп өлгерә, бу хәрбине дә кулга алалар... Әлеге артиллерия училищесы укытучыларын да бер-бер артлы төрмәгә тыга башлыйлар, мөгаллимнәр арасында гади сөйләшүләр дә өзелә... Алар кими бара, саный карасалар, шулай юкка чыккан укытучылар саны, укыту йорты башлыгы белән бергә егерме җидегә тулган икән инде...

Барый Габдулла улы – туры сүзле, дисциплина сөюче, намуслы, кыю, үз һөнәрен яхшы белүче укытучы. Тик ул илдә «халык дошманнары»ның көннән-көн арта баруның сәбәпләрен генә аңлый алмый. Әлбәттә, 44 яшьлек Тухачевскийның төрмәдәге кан таплы язмалары, үз үлеме алдыннан «Яшәсен Кызыл Армия!» дип кычкыруы хакында күпләр бик соңлап кына белачәк әле... Маршалдан илдә хәрби түнтәреш ясарга теләвен әйттергәннән соң башланып киткән репрессия давылы илне канга батырачак. Барый Габдулла улын да НКВДга чакыралар, кулга алынган полковник Бечевкин хакында мәгълүмат бирергә кирәк икән. Барыйга шул көнне рухы сынмаган, әмма кешелек дәрәҗәсе какшатылган хезмәттәшен күрергә туры килә. Ул училище башлыгы Бечевкинның төпле җитәкче булуы хакында гына әйтә ала...

Татар милләтле ир-ат болай да бик күп сүзле булмый. Шул көннән соң ул үз эшенә тагын да тирәнрәк чума, тырышыбрак укыта. Соңрак, сугыш елларында, аның укучылары үзләрен үтә сәләтле командирлар итеп танытачак һәм аңа үз рәхмәтләрен дә белдерәчәк әле...

1941 елның апрелендә Барый Йосыпов Баш командование резервындагы гаубицалы артиллерия полкына юллана. Ул полкны 1941 елның июнендә үк сугышка алып китәләр. Оршага барып җитсәләр, фашистлар инде каладан утыз чакрымда гына икән, әмма совет гаскәрләре ул айларда артка чигенә, аларның полкы оборонага әзерләнә, ләкин чигенү хакындагы фәрман алына. Менә Орша да илбасарлар кулына кала. Тиздән аларның полкын Гороховецк лагерына кайтаралар. Бераздан Б.Йосыпов фронт күләмендәге гвардия миномёт частьларыннан торучы оператив төркем штабы башлыгы итеп билгеләнә.

Сугышның беренче айларында ук ракеталы коралларны кулланырлык сугышчылар әзерләнә башлый. Реактив артиллериянең аерым экспериментал батареясы төзелгәч тә, аның беренче командиры итеп капитан И.А.Флёров билгеләнә. Бик тиздән Барый Йосыпов та «катюша»ларны фронтта иң беренчеләрдән булып сынаучылар рәтенә кертелә. Оператив төркем тиз арада оештырыла. Куәтле яңа корал төре хакындагы хәрби серне беренчеләрдән булып белүче дә һәм хәтта маршал К.Рокоссовский белән күрешеп, сөйләшүчеләрнең берсе дә ул була... Әлбәттә, ул чакта «катюша»лар аз күләмдә әле. Фашистлар аларны тиз арада кулга төшерергә хыяллана. Шуңа күрә «катюша»ларның ут позицияләрен бик тиз арада алыштыру таләп ителә. Хәлләр нык мөшкелләнсә, «катюша»лар дошман кулына эләгергә тиеш түгел, аларны шартлатырга кирәк булачак, дигән фәрман да туа. «Катюша»ларны эшкә җигүчеләр арасында бу боерыкны үтәргә әзер каһарманнар да табыла, ни кызганыч, андый әмерләрне үтәргә дә туры килә. 1941 елның октябрендә Иван Флёров җитәкчелегендәге сугышчыларның юлы киселә, ягулык азая, йөк машиналарның бер өлешен яндыралар, батырлар, шул исәптән 36 яшьлек капитан И.Флёров та Богатырь авылы янәшәсендә засадага эләгә. «Катюша»лар дошман кулына эләкмәсен өчен, аларны үзләре белән бергә шартлаталар, гвардия батареясы тулысынча һәлак була. Бу хакта Барыйга кыр госпиталендәге бер яралы солдат сөйли. Әмма асыл тарихны Йосыпов үз сугышчыларыннан да яшерергә мәҗбүр була.

Б.Йосыпов җитәкләгән төркем батырлыклары башка сугышчыларның да рухын күтәрә, уңышлы һөҗүмнәр саны арта, җитәкче – тәвәккәл, үтә дә җаваплы. Аларга Мәскәү оборонасы белән бәйле орышларда катнашырга туры килә. Землянкада ул генерал-майор И.В.Панфилов белән дә күрешеп сөйләшә. 1941 елның декабрендә Барый Габдулла улы инде «катюша»ларның өченче армия оператив төркеме белән җитәкчелек итә. Сугыш тәҗрибәсен туплап өлгергән подполковник гвардия миномёт частьлары үз көчләре белән разведкага йөрергә һәм разведка күрсәткән җирләргә генә атырга, залптан соң машиналарны тылга ун км ераклыкка чигерергә тиеш дигән әмер проектын әзерли. Хәрби совет аның проектын хуплый, аңа янә Рокоссовскийны күреп сөйләшергә туры килә. Зур җитәкче Б.Йосыповка: «Сезнең «катюша»лар хакында ишеттем һәм сезнең приказыгыз белән дә таныш. Зур эш бу! «Катюша»лар тәүлеккә өч смена эшләргә тиешләр. Аларның залпы кайтавазы рейхстагта ишетелә», – ди.

Ә бер көнне ул 1941 елда һәлак булган якын дусты Сабитны төштә күрә, дусты елмая, нидер әйтмәкче дә була төсле, әмма әйтми... Ә Барый җитәкчелегендәге «катюша»лар дивизионы фронтның төрле җирләренә күчеп, дошманнарга кинәт кенә һөҗүм итеп, аларның өнен алуны дәвам итә.

Бераздан аларның төркемен Төньяк-Көнбатыш фронтка юллыйлар. 1942 елның гыйнварында Иске Руссо янәшәсендәге орышта Барый Габдулла улына укчылар полкы белән дә җитәкчелек итәргә туры килә. Шул тирәдәге фашистлар дивизиясен юк итү бурычы куела. Бу орышта ул танкка граната бәйләмен ата һәм шартлау вакытында снаряд тию сәбәпле кыелган агач ботагы полковникның башына эләгә, сул күзен-

● 1940 ел.

● Барый Йосыпов җәмәгате Һаҗәр һәм улы Нариман белән. 1945 елның 13 гыйнвары.

нән кан ага башлый. Ул каты яраланып, аяктан егыла. Торып, урманга таба атлый башлауга ук, башка танктан ут ачалар. Янәшәдә чәчрәгән ут эремәсе уң күзен һәм маңгаен яндырып ала. Барый танкның ачык люгына граната ыргыта һәм карга егылып, аңын югалта. Туңудан айныгач, ярым сукырайган килеш шуыша башлый, ниндидер авыл йортына барып җитә. Шулчак самолетлар якынлашкан тавыш ишетелә... Кинәт йорт җимерелә, эчендәге хәрбиләр һәлак була. Барый, зәхмәтле дулкынга эләгеп, юл кырындагы кар өстенә барып төшә. Йорт янәшәсендәге мәетләрне күмәргә җыеналар. Штаб писаре мәетләр кырыннан үтеп барышлый, берсенең аякларындагы спорт ботинкаларына игътибар итә һәм аларның полковник Б.Йосыповныкы икәнен танып ала. Аны инде һәлак булган дип уйлаган булалар... Писарь батыр полковникның башкачарак җирләргә кирәктер дип фаразлап, тиз арада штабка йөгерә. Штаб комиссары аның үле гәүдәсен күрергә дип үзе дә килә, комбинезонын чишә башлый һәм батырның исән икәнен чамалый... Полковникны йөк машинасына салып, бер йортка алып кайталар. Пульсы да, сулышы да тоемланмый диярлек, әмма комиссар өч күрше авылны әйләнеп, табибне таба һәм аның өчен мөһим булган столбнякка каршы уколны ясата... Йортны җылытып торалар, янына сак куялар һәм 10 тәүлектән соң ул аңына килә, саташа, ыңгыраша. Шуннан соң каһарманны очкыч белән Мәскәүгә озатып, Үзәк госпитальгә салалар. Барый Габдулла улы исән кала, тик... күзләре күрми. Хәзер аның сәламәтлеге өчен хирург П.В.Мандрыка җавап бирә. Йосыпов Мәскәүдәге туганы Роза Әхтәм кызын чакырта. Ханым аңа теләгән ризыкларын алып килә, палатага яран гөлен дә китереп куя. Ә икенче бер санитарка аңа инде Короленконың «Сукыр музыкант» әсәрен укырга әзер. Татар командирының җәмәгате һәм улы бу вакытта еракта, Казахстанның Талгар каласында яшәп ята. Авырып торган Һаҗәр ханымга ул үз хәлен тасвирлап хат салмый. Улы Нариманны да күптәннән күргәне булмый... Күз табибе А.И.Кураев күзнең мөгез катлавы җәрәхәте сәбәпле барлыкка килгән тискәре үзгәрешне, тапны дәвалый башлый. Сул күз урынына пыяладан ясалган ясалма күз куячаклары хакында хәбәр итәләр. Берникадәр вакыттан соң Йосыповның уң күзе аз-азлап күрә башлый. Бу көннәрдәге кичерешләрен ул соңыннан «Подвиг» исемле китабын язачак Константин Алтайскийга сөйли. Ниһаять, полковник гаиләсенә хат язып сала һәм табибләргә рәхмәтен белдереп, «Красная Звезда» газетасына язма юллый...

1942 елның мартында аңа Ленин ордены тапшырыла. Батырны Архангельское хәрби шифаханәсенә юллыйлар. Мәшһүр сынчы Вера Мухина аны шушы шифаханәдә эзләп таба. Сынчы ханым тиз арада Б.Йосыповның скульптура портретын иҗат итә. Бу вакытта ул сул күзенә кара бәйләвеч бәйләп йөрергә мәҗбүр. Каһарманның бронзадан коелган портретында да ул шушы халәттә чагылдырылган. Портрет бүгенге көндә Третьяков галереясында саклана. Берәздан ул шофер Чагин белән бергәләп Казахстанга, гаиләсе белән күрешү өчен юлга кузгала, каһарман анда улы белән Ыссык күлдә көймәдә йөзә, матур табигатькә соклана.

Терелгәч, «катюша»лар өчен кирәкле кадрларны әзерләү вазыйфаларын үти башлый. Фронтта туплаган үз тәҗрибәсенә таянып, уку программаларын төзи, меңнәрчә сугышчыларга белем бирә. Югары җитәкчелек тә аның мөгаллимлек эшчәнлегеннән һәрчак канәгать була. Нариман, тыныч тормышта геолог булырга теләгән бердәнбер улы да – Бөек Ватан сугышы каһарманы. Ул да хәрби бүләккә лаек дип табыла һәм аңа сугыштан исән-сау әйләнеп кайтырга да насыйп була.

Соңрак полковник җитәкчелегендәге гвардия уку бригадасы Покров янәшәсендәге кырларда уку-өйрәнү җирләрен булдырып, күп көнлек манервлар да уздыра. Ул Покровны төзекләндерүгә дә өлеш кертә.

Тыныч еллар башлангач, 1946 елда Б.Йосыпов Ворошилов исемендәге Химик саклану академиясенең 2 нче факультеты башлыгы урынбасары итеп билгеләнә, әмма андагы эш аның өчен тар кысаларга тиң... 1946 елның сентябрендә баһадирга икенче тапкыр Ленин орденын тапшыралар һәм ул шул айда ук отставкага чыга. Ленин орденнарына, Кызыл Байрак орденына һәм «Ватан сугышы» орденына ия булган мәгълүм зат, Мәскәү татарлары арасында абруйлы шәхес агитатор булып китә. К.Алтайскийның аның батырлыгы турындагы китабында: «Ул чакта башкалада инде 140 меңнән артык татар яши», диелгән. Сугыш батыры мәктәп укучыларына үз хатирәләрен сөйли, ил каһарманнарын искә ала. Бакча эшләрен башкарырга да вакыт таба. Лаеклы ялда яхшы иген үстерү серләренә төшенергә теләп, махсус китаплар укый, Покровның район башкарма комитеты рәисе булып та сайлана....

Ул Әлмәтне дә онытмый, туганнары янына кайтып йөри. 1981 елның 23 мартында Мәскәүдә вафат була. Бүген Әлмәтнең бер урамы аның хөрмәтенә Б.Йосыпов исемен йөртә. Каланың туган якны өйрәнү музеена килеп, әлеге сугыш ветеранының хәрефләрне энҗедәй тезеп язган автобиографиясенә, рәсми кәгазьләренә күз төшерүчеләр аның Ватан-Ананы дошманнардан азат иткәндә фронтның иң алгы сызыгында булган, мәшһүр «катюша»ларны беренчеләрдән сынап тарихка кергән асыл зат булуын искәртә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

● Барый Йосыпов җәмәгате Һаҗәр һәм туганы Галимә. 1943 ел.

Атнаның сәяси мизгелләре

Җаһил дипломатия айлыгы

Апрель аенда БМО Куркынычсызлык шурасында (КШ) Россия рәислек итте. Бу чорга аның планнары зурдан иде һәм ул аңа җитди әзерлек белән дә килде кебек. Әмма кайбер сәяси экспертлар Россиянең бүгенге халыкара проблемаларны үз тышкы сәясәте өслүбендә һәм җаһил алымнар да кулланып хәл итәргә омтылуын да әйтә. Андый алымнар рәтенә КШ әгъзаларының формаль булмаган очрашуын, кайбер башка чараларны да кертергә буладыр. Ә инде җаһил дипломатиянең югары ноктасы дип күпләр ай азагында «Халыкара тынычлык вә иминлекне саклау, БМО Уставы принципларын яклау аша нәтиҗәле күпкырлылык» дигән темага үткәрелгән фикер алышуларны атый. Анда Россия тышкы эшләр министры С.Лавров үзе рәислек иткән һәм һөнәри һәвәслеген дә бөтен тулылыгы белән күрсәткән. Гадәттәгечә, ул анда Украинада бара торган хәрби операциянең максатларын кабатлаган, Вашингтон һәм аның союздашлары мөнәсәбәтләрне яу кырында ачыклауны таләп итүе нәтиҗәсендә, күпкырлылыкка ышаныч югала, дип зарланып та алган. Ул шулай ук БМО КШ реформасын тизләтергә, анда әгъзалар санын Азия һәм Африка илләре хисабына арттырырга чакырган.

Кытай вәкиле Чжан Цзюнь барлык илләрне дә БМО Уставы һәм халыкара хокук принципларына таянып эш итәргә чакырган, БМО аз сандагы илләр мәнфәгатенә хезмәт итә алмый һәм тиеш тә түгел, дип тә өстәгән. АКШны ул гегемонлыкка омтылуда да гаепләгән. Ә РФ тышкы эшләр министрлыгы илнең БМО КШда рәислек итү айлыгын югары бәяләгән.

Сәяси атнаның кайбер башка вакыйгаларын да санап үтик. АКШ Президенты Джо Байден 2024 елның ноябрендә узачак президент сайлавында үз кандидатурасын кабаттан да куячагы турында рәсми төстә белдергән. БРИКСта КАР вәкиле Анил Суклал, оешмада әгъза илләр (Бразилия, Россия, Һиндстан, Кытай, КАР) тышкы эшләр министрларының 2-3 июньдә Кейптаунда узачак очрашуында тагын 19 илнең (алар арасында - Согыд Гарәбстаны, Иран, Аргентина, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Мисыр, Бәхрәйн, Индонезия, Тунис һ.б.) ошбу оешмага кушылу мәсьәләсе каралачагы турында белдергән. Кытай һәм Украина лидерлары телефон аша сөйләшкәндә, аларның Украина буенча тынычлык планнарының уртак яклары тикшерелгән. Ак йортның милли иминлек шурасында стратегик багланышлар координаторы Джон Кирби контрһөҗүм үткәрү өчен Украинага кирәкле хәрби ярдәм АКШ тарафыннан бүген 100% диярлек күрсәтелгәнлеге турында белдергән.

Фоат УРАЗАЙ.

Мәдәни җомга
5 май
№17, 2023

Әмирхан ЕНИКИ

Ана һәм Кыз

Җәй башының шифалы яңгыры, тузанлы юллар өстеннән тыпырдап, җитез генә явып үтте... Иртәнге яшь кояш та таулар шикелле күкнең түренә сузылган кара-зәңгәр болытлар өстеннән ялтырап килеп чыкты. Аның яктылыгы шундый мул, нурларының түгелүе шундый дәртле, җитез иде, хәтта кояш үзе дә бу юмартлыгыннан тынычлыгын җуеп, урынында тик тора алмыйча тибрәнә һәм бер кечерәйгәндәй, бер зурайгандай булып күренә иде. Аның әйләнәсендәге аксыл якты күк, алтын тузанында аунаган үтә күренмәле юка ефәкне кемнәрдер йөгерә-йөгерә җәйгән шикелле, һаман ачыла бара, һәм ераклашкан болытларның күкрәве аның өстен сыйпап, тигезләп үткәндәй тоела иде... Яңгырның соңгы тамчылары җиргә төшеп бетәргә өлгермәс борын, салават күпере дә калыкты. Аның бер башы тау итәгендәге сыек ак томанга төренгән иген кырына терәлгән, икенче башы, киң тугай аша дугаланып, Сакмар өстенә төшкән иде.

Рәхилә, ашыкмыйча гына килеп, урамга караган кечкенә тәрәзәне ачты. Өйнең бүрәнәләренә терәлеп үскән миләш агачының яфракларыннан берничә эре тамчы тәрәзә төбендәге гөлләр өстенә коелды. Бәпкә үләннәре өстендәге, энҗе бөртекләре шикелле, нур чәчрәтеп уйнаган тамчыларның яктылыгы, яңгыр исе белән аралашып, өй эченә иңгәндәй булды... Кинәт кергән һавадан өй түрендәге агач караватның ак чыбылдыгы җилфердәп куйды һәм аның эченнән хәлсез бер тавыш ишетелде:

– Кызым...

Рәхилә тәрәзәдән борылып агач карават янына килде һәм акрын тавыш белән:

– Нәрсә, әни? – диде.

– Чыбылдыкны күтәр... Менә шулай...

Чыбылдык эчендә, ике мендәр өстендә, үтә ябык авыру ана ята.

Ул кансыз юка иреннәре белән көчәнеп елмаерга тырышты, яртылаш ачык күзләренә, әйтерсең, кояшның бер бөртек нуры төште, аз гына җылылык белән елтыраган кебек булдылар. Ул, көрсенеп:

– Менә Алланың рәхмәтле яңгыры, – диде, һәм аның авыру күкрәгеннән сәламәт вакытындагы тавышы чыгып куйды.

Ана күптәннән каты авыру, һәм ул бу урынга инде яңадан тормаска ятканлыгын яхшы белә. Ләкин тыныч җан белән үлемне көткән бу авыру анада соңгы сулышыннан аерылу минутын кичектерү теләге бик көчле: ул улын көтә. Бердәнбер улының фронттан кайтуын, менә шул кечкенә ишектән иелә төшеп керүен, елмаеп янына килүен, «Әни!» дип дәшүен күрергә теле иде. Бу гади сагыну гына түгел, бу – үзеннән соң каласы тормышның дәвамын күрергә тырышу, һәр тамчы каны белән йөрәгә аша үткән ана мәхәббәтен соңгы тапкыр актыгына кадәр улына бирү теләге иде. Ул белә: ана белән ир бала арасындагы мәхәббәт бервакытта да андый ачыклык һәм юмартлык белән тышка чыга алмый. Әгәр менә ир булып җитешкән улы һәрвакыттагыча буйсынып башын игән, тартынып сүзсез торган оялчан кыяфәте белән каршында басып торса, ул бары бер сүз – «балам» дип үрелеп, аның маңгаеннан үбәр иде...

Ананың күңеленә шик киләме?.. Каты сугышның күп корбаннар алуын, кемнәрнеңдер газиз уллары, сөйгән ирләре, кадерле якыннары сугыш кырында торып калуын ул белә. Ләкин аңарда улын күрү ышанычы шундый көчле ки, һичбер нинди шик аның күңеленә кереп урын ала алмый иде. Гүя аның улы нинди генә хәтәр хәлләрдә калмасын, күпме генә ут эчендә йөрмәсен, барыбер исән-сау кайтачак. Бу – шулай, бу – көннең якты, төннең караңгы булуы кебек бәхәссез...

Шулай да Рәхилә, уйланган минутларында бу гамьсезлекне сизеп, үз-үзеннән риза булмыйча, ихтыярсыздан тынычсызлана башлый иде.

Бүген июньнең егерме сигезенче көне... Туганы аның һәр елны шушы числоларда яки июль башларында институттан кайта торган иде. Әнисенең, туганнарының сөеп, сокланып карауларына каршы ул һаман бер сүз белән – гүя аңардан шуны гына сорыйлар – җавап кайтара иде:

– Әни, зачетларымны башкалардан элек биреп бетердем, сезнең янга кайтырга ашыктым.

Былтыр исә ул институтны тәмам бетереп кайтырга тиеш иде. Ләкин өйгә, туганнары янына шундый зур шатлыкның бәйрәмен бергәләп үткәрер өчен кайтасы вакытта, фронтка китеп барды. Ә өйдә аның бу кайтуын көтү әле дә һаман аларның йөрәкләрендә саклана һәрхәлдә, ана бүген, моны исенә төшереп, суз кузгатмыйча калмас.

Һичшиксез, аның газизе кайтыр, кайтырга тиеш!

Анадагы бу ышаныч аның якыннарына да күчкән иде. Кызы Рәхилә, туганы белән төрле хәл булуын исендә тотса да, күңеле төбендә шактый тынычлык тоя. Бигрәк тә ана белән һәркөн туганы турында сөйләшү аның исән-сау кайтуын ничектер уйланусыз, пошынусыз көтәргә гадәтләндерде. Гүя ул фронттан, ут эченнән түгел, ә елдагы гадәте буенча күрше шәһәрдән, институттан каникулга кайтырга тиеш.

Кечкенә өй эче яңгыр белән юылып яшәргән көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек... Миләш агачының яфраклары аша төшкән кояш нурлары, өйнең идән-стеналарын эре-эре челтәрле бизәкләр белән чуарлап, тибрәнеп уйныйлар. Өстәлдәге графинның түгәрәк бөкесе, ачык шкафның тар шүрлегендәге киртләчләренә кыстырган балкашык башлары бу шаян, йөгерешкән нурларны үзләренә җыялар, һәм үзләре дә кечкенә кояшчык шикелле тирә-юньнәренә күз камаштыргыч яктылык чәчеп балкыйлар... Куе-җинел, хуш исле һава, өй эченә берьюлы мул булып керергә теләгәндәй, тәрәзәнең читләренә җыелган ак пәрдәне күтәреп-күтәреп куя һәм һәрнәрсәне иркәләп, сыйпап йөргән кебек тоела.

Ананың бүген кәефе яхшы. Бу шифалы һаваны сулавы аңа җиңел, рәхәт; зәгыйфь тәнендә, никадәр хәлсезләнгәнен сиздереп, ниндидер бер җылымса талгынлык йөри.

Рәхилә, кул эшен алып, тәрәзә янына утырды. Ул авыру анасы белән үзе башлап сөйләшүдән тыела. Ул шулай әнисеннән читтәрәк, аерым бер нәрсә турында да артык уйланмыйча, сүзсез утырырга гадәтләнгән иде. Аның уйлары, аяз күктә өзек-өзек аккан вак болытлар шикелле, акрын, сиздермичә, шәүләсез агалар.

Өй эчендә нурлы тынлык... Ачык тәрәзәдән батыр шаулап зур кара корт килеп керде. Өй эче бер минутка аның көчле безылдавы белән тулды. Ләкин кортка урын тар, кызыксыз күренде булса кирәк, өй эчен бер әйләнде дә кире ачык, иркен һавага чыгып очты. Өйдә янә тынлык урнашты.

Ниһаять, ана башлап дәште:

– Кызым!

– Нәрсә, әни?

Хәсәнемнең соңгы хаты килгәнгә күпме булды инде?

Рәхилә аз гына уйланды:

– Хәзер, әни... Унында алган идек... ике атна тулып узды.

Ана көрсенеп куйды:

– Озак... нигә язмый икән?

Ул яза булыр, тик хәзер бит почта озак йөри.

Ана дәшмәде. Ул сәламәт вакытындагыча айнык-тере булып ачылган күзләре белән көн яктысына карап ята. Тәрәзәдән төшкән яктылыктан аеруча сары булып күренгән йөзендә аның җитди тынычлык һәм нәрсәдер хакында уйлануы сизелә. Гүя, кәефе яхшы, акылы ачык вакытта таркау уйларын җыярга, әйтәсе сүзләрен хәтеренә төшерергә тырыша.

Менә ул кызына текәлеп карап алды һәм янә сабыр гына сүз башлады:

– Кызым, сиңа сүзем бар.

– Тынлыйм, әни...

– Хәсәнемне күргәч, мин күп тормам.

– Әни, нигә алай дисең?.. Хәсән кайтуга син терелерсең...

– Юк, кызым... Хәсәнем кайтканчы торсам, бик шөкер инде. Тик менә куанычымнан әйтәсе сүзләремне онытырмын дип куркам.

– Әни, ул кайткач, без бергә-бергә бик озак торырбыз әле.

Ана хәлсез-ялкау гына елмаеп куйды. Бу елмаюда, гүя, яшь баланың уйланмыйча сөйләнүенә соклану һәм ул сүзләрнең чынлыктан никадәр ерак икәнен ачык белү сизелә иде. Ләкин кызының ихлас күңелдән юатуы аңа ошады булса кирәк, – ул, җиңел генә көрсенеп:

– Кем белә, ходай кушып, бәлкем, терелеп тә куярмын әле, – диде. – Шулай да, кызым, исемә төшкәндә кайбер сүзләремне әйтеп каласым килә.

– Тыңлыйм, әни.

Ана бер генә секунд дәшми торды. Кипкән иреннәре өстеннән теленең очын йөртеп алды. Соңра акрын гына, сүз араларында кыска-кыска гына тыныш ясап, сөйләргә керешә:

– Алты кыз баладан соң мин бер ир бала күрдем...

Ул бик яшь иде әле, без өй эчебез белән ятим калдык. Әтиең, мәрхүм, аны күз алмасы кебек саклап үстерергә васыять әйтеп калдырды. Менә без аны барыбыз да бергәләп үстердек... Тәрбияләдек... Укыттык. Син, ул укысын, кеше булсын дип, йортның бөтен мәшәкатен үз өстеңә алдың, мине карар өчен шушы яшеңә кадәр иргә чыкмый тордың... Инде минем беренче васыятем шул, кызым: Хәсән балам бервакытта да апаларын-сеңелләрен онытмасын, мине якын күргән кебек, аларны якын итсен... Кулыннан килгән ярдәменнән ташламасын. Бигрәк тә сине туган анасы кебек күрсен, синең күрсәткән хезмәтләреңне бервакытта да онытмасын...

– Хәсән туган җанлы бала, әни... Ул тарафтан тыныч бул. Үзең беләсең, ул безнең өчен үлеп тора иде бит.

(Дәвамы киләсе санда).

«Акча исе» чыкса, татар акылын җуя

(Татарстанның халык шагыйре Марсель Галиев белән әңгәмә)

Әдипнең «Кем чираты?» дигән әсәре Бауман урамы турындагы бүлектән башлана икән. Әлеге язылып бетмәгән яңа романда бер өзек бар:

«Үзәк урам – борынгы шәһәрнең талисманы. Башкалабыз Казанның баш урамы – күпне кичергән, язмышлы-узмышлы урам. Ханлык чорында ул – Кремльнең Нугай капкасыннан чыгып, ат тоякларыннан очкын чәчрәтеп, Бөек далага китәсе юнәлеш булган. Ханлык башкаласын нигезенәчә җимертеп, илне яулап алганнан соң, яңадан төзелгән бу урамга «Проломная», ягъни, «Бәреп керү» исемен бирәләр.

Алтын Урда карыныннан чыккан Россия империясен унҗиденче елда йөзтүбән аударып, кабаттан калкыткannan соң, хакимиятне биләп алган большевиклар арасында исем бүлешү башлана; кемгә – шәһәр, кемгә – завод-фабрика, кемгә – урам-мәйданнар. Түнтәрелеш юлында җаны кыелганнарны да онытмыйлар. Менә шул дулкынга эләгеп, Казанның үзәк урамына да «Бауман» атамасы тагыла.

Кем инде ул Эрнест Бауман? Җиңүләр яулаган гаскәр башымы, моңарчы күрелмәгән ачыш ясаган галимме, мәңгелек әсәр язган әдипме? Юк, әлбәттә. Революционер-террорист икән бит!.. Казанның ветеринария институтын тәмамлагач, 1 ел «мал духтыры» булып селкенеп йөргәннән соң, ул илне әчтән таркатырга әзерләнгән революционерлар сафына күчә. Мәскәүдә халык җыелган җирдәге бер митингта (1905) ул, алга чыгып: «Долой бога, долой царя, отныне я сам бог и царь!» – дип акырып җибәрә. Бу тинтәк яһүд алдагы гомерендә нинди явызлыклар кылмас, дигән сизенү белән, бер эшче килеп, аның тимер таяк белән башын сугып яра.

Урам үзе исемен иңеннән кагып төшерә алмый. Аны кешеләр куша. Казанга читтән килгән кунаклар: «Кем ул Бауман?» – дип сорый... Миңа ул сорау мыскыл булып тоела... Аптырагач, болай дим: «Безнең борынгы бабаларыбыз Урал аръягында зур-зур дәүләтләр төзегән. Шул дәүләтләрнең берсендә 551-552 елларда тәхет тоткан Бумын каһан хөрмәтенә кушылган ул», – дип ялганларга мәҗбүр булам».

– Марсель абый, Бауман урамы темасы сезне аеруча борчый булса кирәк, бик усал язгансыз.

– Университет тәмамлагач, 1974 елда Язучылар союзына эшкә кердем. Ул вакытта Язучылар союзы да, Китап нәшрияты, китап сату оешмалары, редакцияләр һәм Тукай клубы да Бауман урамы, 19 нчы йорт бинасында урнашкан иде. Казанның әдәбият-сәнгать Мәккәсе иде ул. Язучылар, композиторлар, рәссамнар барысы да шунда килде – очраша идек. Ниндидер туганлык, бердәм гаилә чалымы бар иде. 1986 елдамы икән – без дә икенче җиргә күчендек, китап нәшриятлары, редакцияләр дә төрле җирләргә таралды. Бауман урамы татарның рухи үзәге булган бинадан коры калды.

Гомумән, соңгы елларда татарны үзәктән куу бара, дип уйлыйм. Бауман башында «Татарстан» кунакханәсе бар иде. Аның башына зур итеп «Татарстан» дип язылган иде. Ул язу юк... «Чәй йорты»н сатканнар, дип ишеттем... Чәй йортының директоры татар хатыны иде бит. Аны ничек алдадылар икән? Анда гел чират була, ризыклары тәмле иде...

– «Татар ашлары йорты»н да саттылар...

– Хәзер анысы да булмаячакмыни? Болар бөтенесе дә бер максат – татарны үзәктән куу. Милли китапханәне кара – университет каршында борынгы бинада иде. Эче-тышы сәнгатьле бизәлгән гаҗәеп бина – нәкъ китапханә өчен эшләнгән кебек иде. Разил Вәлиев аны үзәктә калдыру өчен яңа проектлар эшләтеп тә йөрде. Милли китапханәнең төп бинасын үзәктә калдырырга була иде... Милли архив та читкә күчте бит. Хәзер кеше анда бара алмый. Истанбулда ничәмә ничә миллион кеше яши – Казаннан 10 мәртәбә артык. Анда китапханәләр, архивлар үзәктә. Бауман безнең өчен кадерле урам иде. Исеме түгел...

– Ләкин бит сез аны яклый алмагансыз.

– Кинәт кузгалмады бит. Әле бер оешма китә, әле икенчесе, үзебез дә киттек. Мөштәри урамында бина бирелгәч, сөендек... Сөендерә беләләр бездә. Университетны таркатып бетерделәр. Таркатучысы рәшәткә артындамы? Бөтен ВУЗларны кушып, бутап бетерделәр бит…

– Татар китабы йорты «Ногай» ресторанына әверелгәндә, язучылар тавыш-гауга чыгардымы? Әллә тавыш-тынсыз гына киттеләрме?

– Беркем дә тавышланмады. Аны кисәтмичә генә күчереп бетерделәр. Камал театры күченә, дигән хәбәрне дә авыр кичердем. Фәрит Бикчәнтәев күченүне яклый, диделәр. Нигә алай итә ул?! Татар театры язмышы безне дә борчый бит. Камал театрының яңа проекты рәсемен чыгардылар – адәм мәсхәрәсе. Затлы иләрдә чүп җыя торган җирдә дә андый йорт салынмый. Аларның нинди аргументы булды? Артистларның бүлмәләре бәләкәйме?

– Әйе, артистларга кысан, парковкага урын аз һ.б...

– Артистлар зур апартаментларда утырырлар инде. Асылда, артистның грим бүлмәсендә утырырга да, кофе эчеп ваннада ятарга да вакыты юк бит – көндез репетициядә, кич спектакль уйный.. Грим бүлмәләрен киңәйтерләр, ә менә зал тарайса... анда тамашачы килмәве бар.

– Анысы да уйланган, залны кечерәйтәләр – 500 урын гына калдыралар.

– Татар күченүне яратмый. Бер өйрәнгән җирдән китергә теләмәү аның холкында бар. Йөрмәячәк татар анда. Болар киң грим бүлмәләрендә, кофе эчеп, халыкны көтеп, саргаешып утырачак.

– Ул проектны үз татарларыбыз сайлады. Жюрида кемнәр булуын исемләп саный алам.

– Үзебезнең татарлар әбрәкәйгә охшаган шушы проектны сайлаган икән – димәк, алар сатып алынган. Мин шулай дип уйлыйм. Шулай дип яз!

Татарны сатып алуы бик җиңел – ярлы бит ул, бичара. Әз генә «акча исе» чыкса да, акылын җуя. Киләчәк турында оныта, бүген яшим, дип уйлый. «Татарның үзәге – үзенә дошман» дигән җөмләм бар. Күп нәрсә татар кулы белән эшләнә. Бу очракта читләрне гаепләмим.

– Камаллар киткәч, ул бинага кем керәсен ишеттегезме? Вакытлыча...

– ТЮЗ йөри, ди... Алар үз Ходайларына ялварадыр – татарларга тизрәк бина төзесеннәр дә, алар бу җүләрлекне эшләгәч, без кереп утырыйк та, мәңгегә калырбыз, диләрдер... Әүвәл анда ниндидер башка театрның да күченәсе килә, дигәннәр иде.

– Кариевлар...

– Кариев театры бик зурмыни?

– Труппада 40лап артист...

– Алайса нигә урын кечкенә, дисең? Грим бүлмәсендә биемиләрдер бит?

– Үз Аллалары дигәннән, ТЮЗда да күбесе – татарлар... Телне югалтканнар...

– Телен югалткан татар... алары куркынычрак...

Бауман дигәннән, анда Үзәк банк бар бит. Игътибар иткәнең бар идеме – бинасының ике канаты ике озынлыкта. Архитектура ягыннан карасак, алар бертигез булырга тиеш. Ул бина кырында бер татарның йорты булган. Шуны кузгата алмаганнар. (1914-1915 еллар турында сүз бара. Тарихи чыганакларда «сәүдәгәр Гобәйдуллин йорты» диелгән. – авт.). Әллә ниләр биреп караганнар. Китмәгән! Шуңа банкның бер канаты кыска булып чыккан. Элек акчага кызыкмаганнар. Хәзерге татар акча дигәндә ата-анасын сата.

Без саклый белмибез. Курганнардан чыккан скиф-сармат, һун, төркиләрнең алтыннарын җыйсаң, дөньяда аңа тиңләшерлек байлык юк.

– Алар безнең кулда түгел.

– Татарны хәзер генә түгел, меңәр еллар буена талаганнар. Курганнар Кара диңгез буйларыннан башлап, Монголиягә кадәр сузылган.

– Татар җәмәгатьчелегенең нәрсәне дә булса саклап кала алганмы?

– Юктыр... Хәзер шундый тенденция – үзәктән генә түгел, илдән татар исемен куу бара. Батырлык күрсәткән татарның татар булуын әйтмиләр. Начарлык кылса, «татар!» дип шау итәләр. Кандагардан самолет куып алып кайтучылар арасында да татарлар бар иде. Алар бөтенесе кинода рус геройлары булып чыкты (артистлары – яһүдләр), татарның эзе дә юк (икенче пилот – Чүпрәле егете Газинур Хәйруллин фильмда Сергей дип бирелгән, бу рольне Владимир Машков башкарды. Тагын бер татар егете Әсхәт Габбасов – Оренбург өлкәсенең Куандык районыннан. Бу герой кинода Роман дип бирелгән. – авт). Майор Гаврилов турында кино бар. Ул да кинода татар дип күрсәтелми. Кукуруз басуына самолетын төшереп, йөзләгән кешенең гомерен саклап калган Дамир Йосыповның да кинода татар булуы әйтелми. Бердәнбер «Комеди Клаб»та гына милләтләр әйтелә. Милләтне таный торган бер шул калды, бүтән җирдә танымыйлар.

Икенче бөтендөнья сугышы нигездә Белоруссия, Украина һәм Россиянең руслар яшәгән җирләрендә булды. Сугыш үз җирендә булмаган килеш тә татарлар геройлар саны буенча дүртенче урында тора. Алар тагын да күбрәк булыр иде, 1944 елдан соң татарларга Герой исемен бирми башлыйлар. Ышанмыйча, 2022 елда басылып чыккан «Батырлар китабы»н карадым: Татарстаннан сугышка алынган 141 сугышчыны Герой исеменә тәкъдим ителгән документлар 1944-1945 елларда кире кагылып кайтарыла.

– Моңдый сызлануларыгыз тагын да бардыр әле...

– Казанның бер урамына Борһан Шаһиди исемен бирделәр. Татар өчен ул бернәрсә эшләмәгән. Аны уйгырлар да яратмый. Үзенең милләтен уйгыр дип йөргән. Кытай, рус, уйгыр сүзлеге чыгарган, үз милләтен кертмәгән, моны җинаять дип саныйм. Татар икәнен ни өчен яшергән – аңлый алмыйм.

Рудольф Нуриев үзенең татар булуы белән горурланган, аны ничек кабул иткәннәр! Парижда булганда, гид сөйләп бара: «Людовик XIV яшәгән, Мопассан яшәгән, Бальзак яшәгән һәм Рудольф Нуриев яшәгән Париж», – ди. Ә безнекеләр курка, бичаралар...

– Башкортстан татарлары арасында татар булуын әйтергә куркучылар да байтак, ерак барасы юк...

– Бу мескенлектән котылырга кирәк. Башкортларга республиканы татарлар ясап биргән. Зәки Вәлиди – татар, аның даирәсендә акыллы татарлар була. Татар алфавит ясап биргән, әдәбиятны, сәнгатьне бар иткән. Мостай Кәримнең башкортча сөйләгәнен ишеткәнем булмады. «Мин – татар, башкортка эшлим», – дип әйтеп булмыймыни?! Ключарев рус иде, татарга эшләде бит.

– Бүген менә шулар борчый мине.

– Син хәзер Сәйдәш маршы уйнатып китеп бара торган «Татарстан» поездының юклыгын беләсеңме? Хәзер андый исемдәге поезд юк!.. Дөрес, минем күптән поездга утырганым юк. «Татарстан» язулы поезд «широкая душа» дип мактанырга яраткан рус җирләреннән үткәндә, андагы халыкның «киң күңеллелеге»нә тигәндер, бәлки. Һәр вагонга зур итеп «Татарстан» дип язылган булуына түзә алмаганнардыр...

– Бауман урамында әлмә такталарын да татарчалаштыра алмадылар бит, законы юк, ди.

– Хәзер алга таба инглизчә язмаслар инде, чит илләргә каныккан вакытта шуны файдаланып калырга кирәк – татарча язарга... Президент тирәсендә дә милли мәсьәләләрдә акыллы кешеләр булырга тиеш. Югыйсә, аны беркатлы дип тә уйлаулары мөмкин. Ә ул – финанслар галәмен бик әтрафлы белгән, дөньяның кая барганын аңлый торган шәхес. Җиңел генә бирешә торган түгел.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

intertat.tatar

(Дәвамы. Башы 16 нчы санда).

Ниндидер юллар белән Иркутскига аның белән элек Брест каласында хезмәт иткән бер офицер да килеп чыккан, шул кеше Гавриловка аның беренче хатынының Кстово каласындагы госпитальдә ятуы турында хәбәр иткән. Гаврилов Кстовога барып, түшәктә ятучы тәүге хатынын да үз гаиләсенә алып кайткан. Ләкин бичараның гомере санаулы булган инде, 1956 елда Гаврилов аны ләхеткә иңдергән. Шуннан соң хәрби хезмәт белән араны өзеп, туган авылы Әлбәдәнгә

● Витебск районының Копти авылындагы мемориал комплекс.

● Копти комплексына Татарстан хөкүмәте китереп куйган һәйкәл.

КАЗАННАН БРЕСТКА СӘЯХӘТ

кайткан. Ләкин анда «хыянәтче, немецларга үз теләге белән әсирлеккә төшкән» дип битенә төкерүләр, йорт салырга да рөхсәт итмәгәч, яр буенда землянка казып, шунда җәфалану. Һәм күк йөзендә көтелмәгән кояш – 1957 елда Советлар Союзы Каһарманы дигән дәрәҗәле исем!.. Күңеле кайткан Гаврилов туган авылында яшәп кала алмаган, Краснодар шәһәренә китеп барган. 1971 елда герой Брест крепостен ачу тантанасы. 1979 елда инде вафат. Ядкәрнамә язганда, үзен Брест каласында җирләүне үтенгән. Кабере Брестта, герой крепость янәшәсендә булдырылган гарнизон каберлегендә. Каберенә китерелгән чәчәкләрнең шиңеп торганы юк... Гавриловлар тәрбиягә алган Николайдан ике малай яшәп калган, диләр. Музейныкылар бертуктаусыз эзләнү алып бара, аваз салучы юк. Мәрхәмәтсез тәкъдир...

Яшьлегендә Брест крепостен яклап сугышкан, ә олыгайгач һичкемгә кирәге калмаган Тимерҗан ага Зиннәтов, Советлар Союзын юк итүләренә һәм сугыш ветераннарының Ельцин-Гайдар хөкүмәте өчен кадерсез йөккә әйләнүенә протест йөзеннән, Брестка килеп үз-үзен шартлатып юк иткән һәм крепость зиратына җирләүләрен үтенеп язу калдырган. Әмма Туймазыда үскән әлеге каһарманның

● Дубровно район үзәгендә Фәрит Яруллин бюсты.

җәсәден шәһәр читенә озатып котылганнар...

Брест крепосте үзәгендә бүген мәңгелек ут яна. Янәшәдә туганнар каберлеге, анда 1038 җәсәд җирләнгән. Арада татарлар да бар. Тик исемнәрен дә дөрес итеп яза белмәгәннәр. «Салгереев Хаким Сапович» бар. Ә дөресе – Сәлимгәрәев Хәким Сафа улы, юкса... Гаиләсе белән һәлак булган Александр, Мария һәм аларның нәни улы Дима Шаряклар исеме язылган мемориал такта янында йөрәк кысып ала. Яшь-яшь көенчә башын салган шәфкать туташларының исемнәрен уку да дәва түгел...

● Рыленки мемориалында Фәрит Яруллин аерым күрсәтелгән.

Әле үзәк каберлектән тыш, Көнчыгыш фортта, Ак Сарай хәрабәләре, Көнбатыш форт янында табылган каберлекләр дә бар. Брест крепостеның һәр карышы кан белән сугарылган. Биредә адәм балалары гына түгел, бомбалар дәһшәте астында кирпечләр дә эреп яшь агызган...

Белоруссия 1944 елның июнендә кадәр немец фашистлары кул астында булган. Оккупация вакытында биредә дистәләгән партизан отрядлары хәрәкәт иткән. Беренче Беларусь бригадасын Витебск өлкәсендә – «Батька» кушаматы алган Михаил Шмырев (әлеге партизан бригадасы турында «Батька» исемле нәфис фильм да төшерелгән), Орша ягындагы икенчесен Константин Заслонов җитәкләгән. Шул Заслонов отрядында соңыннан күренекле шагыйрь булып танылган Зәки ага Нури разведка бүлеге башлыгы булып йөргән. Партизаннар барысы да соңыннан Кызыл Армия сафына кушылган, бергәләп Белоруссия җирләрен азат итү өчен көрәшкәннәр. Фашистлар коточкыч каршылык күрсәткән, моны Рыленки һәм Копти мемориал каберлекләргә күмелгән корбаннар саны раслый. Рыленкида 10 меңнән артык совет солдаты җәсәде, Коптида – 6 чакрым арада кырылып беткән 11 мең 400 солдат. Белоруссияне азат итү хакына башын салган совет солдатларының гомуми саны 600 меңгә җитә. Әлегәчә күбесенең исем-фамилияләре дә билгесез. Михаил Черепанов җитәкләгән

● Генерал М.Ефремов яу алдыннан. 1942 елның кышы.

● Вязьма каласы үзәгендә генерал М.Ефремов хөрмәтенә куелган һәйкәл.

● Копти мемориалында Василий Сталин хөрмәтенә куелган һәйкәл.

Мосафир сәфәрдән кайтты

● Минскида үзәк урамнарның берсе.

● Минск – герой-кала.

●Минскида Бөек Ватан сугышына багышланган яңа музей-комплекс.

● Минскида спорт төрләренә багышланган «кораблар»ның берсе.

● Минскида президент төзеткән Бәйсезлек сарае.

● Минск уртасында Свечлов елгасы яры.

«Хәтер фонды» Белоруссияне азат итү өчен һәлак булган 14 меңгә якын татарстанлының гына исемнәрен ачыкларга өлгергән, ә алар саны 30 мең чиген үтеп китә. Копти каберлегендә бертуган Яков белән Василий Сталиннар истәлегенә аерым һәйкәлләр куелу бик гыйбрәтле. Һич урынсыз түгел: Яковы шушы җирне яклап сугышканда фашистлар кулына әсирлеккә төшкән, ә Василий полкы 1944 елда Белоруссияне азат итүдә катнашкан. Сабагы шул: ул чактагы ил башлыгы хәтта үзенең газиз уллары да ил сагына куган. Ә бүгенге олуг түрә вә депутатларның угыллары, прокуратура, суд, хакимият кебек оешмалардан бер генә вәкил яки аларның туганнары да солдат каешы дигән ядкәрнең ни икәнен дә белми...

Бөек Ватан сугышының бар дәһшәтен чамалау-тою өчен, Вязьма каласына да сәяхәт итү кирәк. Без анда да булдык, шәһәр башлыгы Инна Демидова үзе кабул итте. Бу кала урамнарын йөрәгең «жу» итмичә генә атлап чыгу да кыен. Шушы каланы да үз эченә алган Вязьма-Ржев казанында бер миллионнан артык совет солдаты юк ителгән. Әсирлеккә эләккән йөзәр меңләгән совет солдаты гитлерчылар төзегән концлагерьларда газап чиккән. Ә 1942 елның язгы чәчүенә кадәр дошманны совет иленнән куып чыгару белән җенләнгән Сталин һәм Жуков гыйнвар аенда ук Волхов казанына генерал-лейтенант Власов җитәкләгән 2 нче армияне, ә аннан соң Вязьма казанына генерал-лейтенант Михаил Ефремов командалыгындагы 33 нче армияне куып керткән. 2 нче армиядәге 390 мең солдатның 32 меңе, ә Ефремов армиясеннән нибары 880 чамасы гына солдат исән чыккан. Вязьма казанына аннан соң да өч армия һәм тугыз ополчение дивизиясен ташлаганнар, алар яуда ит урынына туракланган, хәтта соңыннан төшерелгән нәфис фильмнар да андагы дәһшәт һәм мәхшәрне яшереп кала алмый.

Генерал Ефремовның үзен коткару өчен Сталин юллаган махсус самолетка утырудан баш тартуы да төгәл сурәтләнгән. Яулар барышында дүрт тапкыр яраланганнан соң, сугышчыларына камалыштан чыгуда йөк булмау өчен, үзен-үзе атып үтергән ул. Аның гәүдәсенең кайда ятуын күрсәткәч, немец генералы Модель, ике якка совет тоткыннарын һәм үз солдатларын бастырып, Ефремовны тантаналы рәвештә җирләүне оештырган. Бөек Ватан сугышы барышында гы мондый бердәнбер очрактан әле еллар буе особистлар кер эзләп азапланган, Ефремовка яла ягардай җай тапмаган. Ә аның исән калган солдатлары 1945 елның Җиңү бәйрәменнән соң Вязьма каласына җыелган. Ул чакта Вязьманың шәһәр диярлеге дә калмаган, әлбәттә. 51 исән калган йорт һәм элеккеге 30 мең урынына 2 мең исән калган кеше. Ефремовчылар шәһәр башлыгын чакырып чыгарган да, үз орденнары өчен айлар буе җыелган акчаны тезеп салган һәм башлыктан үзәк мәйданны генерал исеме белән атауны һәм бер ел эчендә аның хөрмәтенә һәйкәл куйдыруны таләп иткән. Мондый «башбаштаклык» турында Сталинның шәхсән үзенә рапорт ясаганнар, ә ул Ефремов һәйкәленә конкурс игълан иткән. Ярышта Вучетич проекты иң отышлы дип табылган һәм 1946 елның 7 ноябрендә үк һәйкәлне ачу тантанасы да оештырылган. Үз командирлары өчен бу кадәр җан атып йөргән башка солдатларны тарих әлегәчә белми. Бүгенге генераллар ошбу хакта хыялллана да алмый...

Татарстанда да 1941-1943 еллар дәвамында җиде дивизия оештырылган бит, алар арасыннан 18, 86, 334, 352 нче дивизияләр Белоруссияне саклап калу һәм азат итү өчен канлы яуларда катнашкан. 18 нче дивизия сугышчылары 1941 елның 9 июленнән 18 июльгә кадәр Белоруссиянең Орша белән Витебск шәһәрләре арасында 40 км киңлектәге рубежны саклаган, исән калганнары 23 июльдә Смоленск өлкәсенең Ярцево шәһәре янында чолганыштан чыгып, совет гаскәрләре сафына кушылган. Дивизия составында 2100 чамасы хәрби исәпләнсә, аларның 1200 дән артыгы Днепр елгасы ярларын дошманга бирмәү өчен сугышып һәлак булган, 844 е әсирлеккә төшкән. Дивизиядәге 2100 солдатның 637 се татар, исемнәрен генә ахырынача ачыклап бетерүчеләр табылмый.

86 нчы укчы дивизия дә сугыш башында Белоруссия хәрби округының Белосток шәһәре тирәсен – Нарва елгасы ярларын, Сураж һәм Лапы калаларын яклаган, ләкин әлеге дивизиянең дә 444 сугышчысы яуда һәлак булган, 124 е әсирлеккә төшкән.

334 нче дивизия, оештырылган көннәреннән үк, әүвәл Мәскәү өлкәсенең Подольск, аннары Тверь каласын азат итү өчен кан коя. 1943 елның ноябреннән башлап 1944 елның декабрь аена кадәр дивизия Белоруссия җирләрен азат итүдә катнаша. Дивизиянең 10 сугышчысы Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, аңа Витебск дивизиясе дигән мактаулы исем бирелә. 1812 елгы Ватан сугышында да составы буенча яртылаш татар җайдакларыннан торган ике «башкорт» полкы шушы Витебск каласын Наполеон солдатларыннан азат итү өчен сугыша. 1942 елда Польшаның Едлино лагерында оештырылган «Идел-Урал легионы»ның 825 нче батальонындагы 506 исән калган солдат та нәкъ шушы Витебск каласы янында фашист офицерларын юк итеп, совет партизаннары ягына чыга. Шул мисалдан соң гитлерчылар башка батальоннарны совет гаскәрләренә каршы юлланы туктата, әмма, ни кызганыч, партизаннар ягына чыккан каһарманнарны да особистлар тора-бара юк итеп бетерә...

352 нче дивизия 1941 елның көзендә Бөгелмә каласында оеша. 1943 елда Смоленск өлкәсен, 1944 елда Белоруссияне азат итүдә катнаша. Орша каласы янында күрсәткән каһарманлык өчен дивизия «Орша» дигән мактаулы исемгә лаек була. Дивизия сугышчылары Минск каласын азат итүдә дә катнаша. Әмма яулар барышында дивизия 1368 сугышчысын югалта, 207 солдат яралардан үлә, 24 е әсирлеккә эләгә...

(Дәвамы 14 нче биттә).

Мәдәни җомга
5 май
№17, 2023

КАЗАННАН БРЕСТКА СӘЯХӘТ

(Ахыры. Башы 12 нче биттә).

● **Минск урамнарында «тояк тавышлары», яки «Җиктереп пар ат Казанга...»**

Белоруссияне азат итү 1944 елның 23 июнендә Генераль штаб башлыгы, керәшен татары Алексей Антонов әзерләгән «Багратион» операциясе белән башлана. Дошман полкларын тармар итүдә каһарманлык күрсәткән татар Геройларын да искә алыйк. Очучылар солтаны булган Әмәтхан Солтан белән Башкортстанның Илеш районында туып үскән татар Муса Гәрәев Белоруссияне азат итү өчен сугышларда икенче мәртәбә Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Алардан тыш, Татарстанның Балтач районында туып үскән Вәсил Булатов, Свердловск өлкәсеннән чыккан Дмитрий Гайнетдинов, Башкортстанның Чишмә районында туган Габдулла Гыйззәтуллин, Курган өлкәсе егете Хәмзәән Гыйззәтуллин, Актаныш районының Татар Әҗбие авылыннан Баян Дәүләтов, Башкортстанның Благовар районыннан Бакир Дәүләтов, Омск өлкәсенең Исилкүл авылыннан Искәндәр Даутов, Астрахань каласыннан Ибраһим Дубин белән Исмәгыйл Йосыпов, Төмән өлкәсенең Тархан авылыннан Анзар Кәлиев, Татарстаннан Галләм Морзаханов, Бакалы районыннан керәшен Михаил Петров, Томск каласыннан Шамил Рәхмәтуллин, Куйбышев каласыннан Ольга Сәнфирова, Кырымның Тау-Кыпчак авылыннан Сәетнафә Сәетвәлиев, Пермь өлкәсеннән Лотфулла Сибгатуллин, Бәләбәйдән Мәгубә Сыртланова, Минзәлә районының Бикләп авылыннан Гамир Һадимөхәммәтов, Саба районыннан Вәли Хаҗиев, Яшел Үзән районыннан Хәлил Хәйруллин, Тукай районыннан Кәлимулла Якупов, Төмән өлкәсеннән Булат Җантимеров батырлыклары Алтын Йолдыз белән бәяләнә. Аларның берничәсе Белоруссия җирләрендә ятып кала, исемнәре мемориал такталарга язылган. Ә Әстерханда туып үскән татар каһарманнарының исеме хәтта иң кыска тыкырыкларга да лаек була алмаган...

Хәзер инде Белоруссиягә ясаган сәяхәт турында кыскача йомгак ясарга да бик вакыттыр. Дүрт тәүлек эчендә бар җирне дә күрдек, дип күкрәк сугып булмый, әмма күргән кадәресе дә – олы сабак. Минск каласында гына түгел, Брест, Витебск, Дубровно, Волковичи – һәр торак буенча көндез чыра яндырып эзләсәң дә, сыңар гына чүп кисәге дә табып булмый. Хәтта ышану да читен: юл читләренә, урманнардагы агачлар арасына да газон чирәме утыртып чыкканнар сыман. Шәһәрләрдәге бөҗралар, юл борылмалары, һәр чат саен яшел чирәм, туя түтәлләре. Минскида бер-берсе өстенә яки бер-берсенә терәп салган сыңар йорт та юк. Һәр тарафта иркенлек, пөхтәлек, европача үлчәм. Йортлар игезәкләрдәй тезелешеп тормый, дистәләрчә төрле архитектура үрнәкләре. Тыштан түм-түгәрәк булып торган йортлар да, ихатасы эчтә калдырылып, подъездлары бөҗра урынына әйләндереп алган йортлар да бар. Ислач елгасы яры буенча тезелгән спорт корылмалары – аерым зур бистә. Футбол, хоккей, гимнастика академияләре, көймәләрдә йөзү, мылтык яки җәядән ату, биатлон, чаңгы спорты буенча төзелгән биналар – яр буена тезелеп баскан аерым кораблар кебек. Шәһәрне икегә бүлеп аккан Свечлов елгасының ярлары – ял парклары урыны. Анда яшел чирәм уратып алган брусчаткалы аллеяларда Пушкин яки Гоголь һәйкәлләре, йөзәрләгән аркалы скамейка, ә елгада аккошлар һәм кыр үрдәкләре, акчарлак, күгәрченнәр...

Минск сугыштан соң яңадан төзелгән бит, хәтта Сталин заманында калыккан йортлар, профсоюз сарайлары, «Европа» кунакханәсе, Советлар Союзы мәйданында иң беренче булып ике мәртәбә Советлар Союзы Каһарманы дәрәҗәсенә ирешкән Сергей Грицевец һәйкәленә кадәр – барысы да гүзәл. Иң гаҗәбе – боларның урамнарында сыңар гына да полицейский очратмадык, ике-өч мәйдан яки борылышларда гына ГАИ машинасы туктап тора иде. Илләрендә колхоз һәм совхозлар, терлек фермалары нәкъ совет хакимияте чорындагыча яшәвен дәвам итә, мәктәпләрнең яшь буыны пионер галстуклары тагып йөри. Минскида ике миллион чамасы кеше яши, бистәләрен дә кушып исәпләсәң, 2,7 млн. Ләкин боларның сыңар гына урамына да Казандагы кебек аерым гаилә вәкилләре хуҗа түгел, аларда мәйдан яки кунакханә, сарай тирәләрен тәрәзәләренә камералар куелган махсус машиналар урап һәм штраф сылап йөрми. Белорусларда үз халкын, газиз халкын талап яшәүче сорыкортлар юк!

Тагын бер гаҗәп як – белоруслар Кавказдан килгән әрсезләрне дә, Урта Азиядән килгән талымсызларны, Кытай яки Вьетнам килмешәкләрен – сыңар гастарбайтер да кертмичә гомер итә. Үзебез күреп тордык: брусчаткаларын да белорус егетләре түши, юл читенә яңа агачларны да белорус утырта, урамнарны шулар җыештыра, автобус һәм троллейбусларны да белоруслар йөртә. Күршеләрдә, әнә, Мәскәү каласына гына да бер миллионга якын таҗик, бер миллион кыргыз, өч миллионга якын кавказлыны кертеп тутырдылар. Барча урамнарны шулар җыештыра, барча троллейбус-трамвайларны шулар йөртә. Ә Мәскәү читендә яңа мәчет калкытыйк, мәркәздәге 6 млн мөселманга дүрт кенә мәчет туры килә бит, дисәләр, тот капчыгың, әрәмтамак булып яткан яки кибет төбендә тиеннәр сорашып йөргән җыен сәрхүш каршы ябырыла: «Рус иле – руслар өчен, башкаларга көн юк». Тик әллә нишләп солдатлыкка гына бурят белән тывалыны яки татар белән башкортны озаталар, Мәскәү белән Петербург каласыннан окопларга чакырулы егетләр юк...

Белоруссиядән кайтырга чыгуга ук, Смоленск җирләрендә исерек урманнар башлана. Иген чәчелмәгән, сабан йөзен күрмәгән басулар – йөзләрчә мең гектар. Котырынып үскән кура һәм үлән калдыкларыннан котылырга кирәк бит, бер басу читенә ике янгын сүндерү машинасы, ике төрәнле трактор китереп бастырганнар да коры үлән дингезенең читенә ут төрткәннәр. Урманчы һәм полиция киемнәренә киенгән ирләр карап тора, ә каршыларында йөзәрләгән гектар үлән яна. Алар юкка чыккач, яңа чирәм калкып чыгачак, юлдан узучыларның «басуларда уҗым» дип уйлап үтүе бар. Хәер, Смоленск, Владимир өлкәләрендә иген басулары турында кайгыртучы да юктыр. Владимирның Афонино, Крутово, Ситино, Хитрово дигән авыллары янына санап үттек: кичә генә 15-20 булып утырган йортларының 4-5 ендә генә гаиләләр яши, ә бушаган, ташланган йортлары алгы яктан киртәгә менгән әтәчтәй кукраеп утырса да, арткы яктан авып бара яисә бөтенләе белән җимерелгән инде. Ышаныгы читен: бездә адәм баласының гына түгел, агач һәм җирнең дә өч тиенлек кадере юк. Шуның өстенә дә «Безнең югары технологияне Кушма Штатлар урлап бетерә!» – дип әрсез рәвештә сөрән салалар бит...

Белоруссия басуларында ашъяулык кадәр иген җире дә эшкәртүсез яки орлыксыз калмаган. Менә кайда үрнәк!..

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

● **Әсирлеккә төшкән совет солдатларын поезд белән Германиягә куу. Сентябрь, 1941 ел. Вязьма.**



● **Вязьма җирендә корылган балалар концлагере.**

● **Концлагерьларда газапланучы совет солдатлары.**

МИЛЛӘТ ТЕЛСЕЗ БУЛА АЛМЫЙ

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

Башкортстанның Бишбүләк районы фольклор ансамбльләре Казандагы съездга килүчеләрне җырлап-биеп каршы алды. Оешма балалар белән дастаннар өйрәнү эшен дә башлап җибәргән. «Дастаннар авыр тел белән язылган. Әмма китапханәчеләр, ансамбль җитәкчеләре аларны җиңеләйтеп аңлата. Шуңа да балалар бик яратып йөри. Кызганычка, бу китаплар бик аз, аларны табуы авыр, без аларны ксерокс аша чыгарып таратты. Җиңүчеләргә Йосыф китабын бүләк иттек», – ди Люция ханым. Бүлекчәләрдә татар театр коллективлары оештыра башлау да милләттәшләребезне берләштерә. «Алар куйган спектакльләрне, фольклор ансамбльләре чыгышларын карау өчен халык залны тутырып килә. «Балалар бакчалары белән эшлибез. «Татар кызчыгы», «Татар малае» дигән конкурсны уздыргач, балаларның гына түгел, әти-әниләрнең дә татарча сөйләме яхшырды», – ди Л.Вафина. Башкортстан татар хатын-кызларының «Ак калфак» берләшмәсе Туймазыда алтынчы ел «Җырлыйк әле» татар фольклор фестиваль-бәйгесен үткәрә. Җиңүчеләр Конгресс тарафыннан сәхнә костюмнары белән бүләкләнә. Ансамбльләрнең яшәрә баруы да – күңелле күренеш. Чөнки коллективларның чыгышында балаларның да катнашуы таләп ителә. Җаваплылыгы чикләнгән «Оренбург шәлләре» җәмгыяте директоры, өлкәнең «Ак калфак» оешмасы рәисе Альбина Әбсәләмова үз чыгышында Оренбург якларында элек-электән данлыклы иганәче байлар бертуган Хөсәеновлар, Рәмиевләрне, замандашларыбыз Мәдинә Рәхимкулова, Рәшит Искәндәровны искә алып үтте. Аларның илгә-көнгә күрсәткән хезмәтләре санап бетергесез. Байларыбыз үз заманында мәчетләр, мәдрәсә-мәктәпләр ачканнар, газета-журнал, китаплар бастырганнар, халкыбызны мәгърифәтле итү өчен эшләгәннәр. «Оренбург өлкәсе эшмәкәрләре белән берлектә «Туган авылым», «Татар кызчыгы», «Татар малае», «Шәл туе», «Әбием сандыгы», «Ак хисләр» проектлары гореф-гадәтләребезне, телебезне, йолаларыбызны саклау ниятеннән үткәрелә. Өлкәнең «Ак калфак» оешмасы җыеннарында бергәләп киңәшәбез», – ди Альбина ханым.

Оренбург ягында гаиләләре белән эшмәкәрлекне, иганәчелекне үз иткән татар гаиләләр дә шактый икән. Кемнәрдер чәкчәк пешерә, икенчеләре «Татар халык ашлары» компаниясен булдырган. Фермер буларак эш иткән, сәүдәгәрлек белән шөгыльләнгән гаиләләр бар. «Оренбургның булдыклы татарлары милләтебезнең дәрәҗәсен күтәрә», – ди ул. Альбина һәм Фаил Әбсәләмовлар үзләре дә – «Оренбург шәле» фабрикасы хуҗалары. 1999 елда дистәләрчә шәлдән башланып киткән эш еллар белән үрчегән, киңәйгән. Хәзер аларның шәл бәйләү процессының һәр этабы – үз кулларында. Гаиләнең башлыгы Фаил мамык кәҗәләре үстерсә, ике авылның халкын эш белән тәэмин итеп торса, Санкт-Петербургта белем алган өлкән уллары Тимур мамыкны тарау, юу, эшкәртү, эрләтү кебек процесслар өчен җаваплы. Альбина ханым аларны бәйләүчеләргә тарата. Уртанчы уллары да тиздән белгечлек алып кайтачак. Мәктәптә укучы кече кызлары Азалия исә күптән шәл бәйләү остасына әверелгән. Алай гына да түгел, Әбсәләмовлар шәлче осталарның эшен дәвам итү ниятеннән өлкәнең дүрт районында мәктәп балаларына бәйләү серләренә өйрәтә. Милли гореф-гадәтләребезне, телебезне саклауны күздә тотып үткәрелгән чаралар, «Ак калфак» оешмасы проектлары Әбсәләмовларның иганәчелек ярдәменнән башка үтми. Моннан тыш Әбсәләмовлар, авылларны эшле итеп, аны юкка чыгудан да саклап кала.

●Ярминкә бизәкләре.

Төркиянең Истанбул шәһәре Идел буе-Урал татарларының мәдәният һәм үзара ярдәмләшү җәмгыяте әгъзасы, журналист Айзирәк Гәрәева-Акчура шул яклардагы татар авылларында сакланып калган фольклорга күзәтү ясады. Хәзер инде мөһаҗирләрнең дүртенче-бишенче буыны, алар арасында үз телләрен саклап килүчеләр дә бар. Алар әти-әниләреннән отып калган җырларны да башкаралар.

Милли Шура рәисе В.Шәйхразыев пленар утырышны йомгаклаганда, татар телен саклауны хәзерге буынның төп бурычы, дип билгеләде. «Татар теле – ана телебез. Кеше бәлки телсез була аладыр, ләкин милләт телсез була алмый. Татар халкы меңләгән еллар яшәп, үз телен, милләтен саклап калган икән, бүген аны киләчәк буынга тапшыру – безнең төп бурыч. Шәҗәрә буенча җиде буыныңны белергә кирәк, дибез. Аны белү генә аз. Аны балаларның, оныкларның йөрәкләренә, кем булган синең әби-бабаң, дип күңелләренә ярып салырга кирәк. Җиңел гамәл түгел. Безнең милләткә кайсы вакытта җиңел булды соң?»

Ул милләтнең киләчәге хатын-кызлар кулында булуын да аерым билгеләп үтте. «Балаларыбызга милли тәрбия бирү, телебезне саклау алга таба да сезнең кулда булачак. Әгәр кыз бала әти-әнисенең тәрбиясен, аларның кулын тоеп үсми икән, ул киләчәктә баласы белән нәрсә турында сөйләшергә тиеш? Үз әтисеннән алмаган тәрбияне ул ничек тапшыра алыр? Ныклы гаиләләр кирәк», – диде В.Шәйхразыев.

III Бөтендөнья татар хатын-кызлары җыенының пленар утырышында координацион совет җитәкчесен һәм аның урынбасарларын сайладылар Кадрия Идрисова татар хатын-кызлар хәрәкәтенең координацион совет җитәкчесе итеп сайланды.

Икенче көнне делегатлар һәм кунаклар «Бала-Сити», «Алта скул» шәхси мәктәпләренә барып, андагы эш, тәрбия үрнәкләре белән таныштты.

Шул ук көнне «Корстон» сәүдә-күңел ачу үзәгендә «Татар гаиләсендә 3 буын һәм 7 буын хәрәкәте», «Татар гаиләсендәге тәрбия» «Татар гаиләләрендә эшмәкәрлек», дигән темаларга секция утырышлары узды. «Татар гаиләсендәге тәрбия» дигәнен танылган фольклорчы, филология фәннәре кандидаты Фәнзилә Җәүһәрова алып барды. Ул «Татар ядкәрләре» оешмасы эшчәнлеге һәм йолаларыбыз белән таныштырды.

Оренбург өлкәсенең Татар Каргалысы мәктәбе директоры Тәүһидә Низаметдинова Казаннан һәрвакыт рухи баеп, тәҗрибә туплап кайтулары турында сөйләде. «Хәзер Каргалыда да балаларыбыз русча сөйләшә», – ди ул. Ул унөч еллар элек Казанның 2 нче гимназиясендә булган. Анда ул вакыттагы директор Камәрия Хәмидуллина балаларга «Татар җыры» фестивале үткәрүләре турында сөйли. Аларның ун ел уку дәверендә кимендә ун җыр өйрәнүе турында әйтә. Бу фикер Тәүһидә ханымга да ошый. Былтыр Татар Каргалысы мәктәбендә бу фестиваль 13 нче тапкыр үткәрелгән. 700 бала, татарча җыр өйрәнеп, туган телендә җыр башкара. Аларның әти-әниләре дә бу хәрәкәткә кушылып китеп, ул-кызларына милли киемнәр тектерә.

●«Дастан туе»ннан күренеш.

Татарстанның халык артисты, М.Җәлил премиясе лауреаты Гөлзада Сафиуллина балаларыбызны, мәшһүрләребез турында сөйләп, горурлык хисе белән үстерергә кирәклеген белдерде. «Җәлил батырлыгын белгән бала үзенең татарлыгы белән горурланып үсәчәк», – ди Гөлзада ханым. Эстониянең «Идел» татар мәдәнияте җәмгыяте җитәкчесе урынбасары, Таллин җирле радиосында татар телендәге тапшыруларны алып баручы Фәүзия Һадиуллина бу якларга 1979 елда тормышка чыгып киткән. 35 елга якын чит милләт арасында яшәгән ханымның сөйләмендә аз гына да акцент юк. Алай гына да түгел, балалары, оныклары татарчаны бик яхшы белә, туган телебездә бик матур итеп сөйләшә икән. Хәтта чит милләттән булган кияүләрен дә татарчага өйрәткәннәр. Үрнәк шулай туган.

Хатын-кызларыбызның эшчәнлегендә тагын бер таяну ноктасы – «Калфак туйлары». Бу кичәләрдә мәшһүр хатын-кызларыбыз өлге итеп алына. Әйтик, аның беренчесе илче, Болгарда төрле илләрдән килгән кызлар өчен мәдрәсә тоткан, хан нәселеннән булган Туйбикә абыстайга багышланганы истә калды. Икенчесендә Болгар халкының азатлыгы көрәшендә катнашып, легендага әйләнгән Гайшәбикә, Казан тарихында Нурсолтан, Сөембикә ханбикәләр турында хатирәләр яңартылды, дүртенчесе татар тарихындагы мәгърифәтче хатын-кызларның лаеклы дәвамчысы, төрки дөньяга билгеле Рәшидә абыстай Исхакыйга тәгаенләп үткәрелде.

Бөтендөнья татар конгрессы 2023 елны Дастаннар елы дип белдергәнлектән, быел «Калфак туе» да шушы темага багышлап үткәрелде. Сценарийн Алмаз Нургалиев әзерләгән кичәдә халкыбызның мирасы 1000 елдан артык тарихы булган кыйссалар, дастаннар искә алынды. 1369 елда Идел буе шагыйре Хисам Кятибнең мәгълүм сюжетка нигезләнеп язган «Җөмҗөмә солтан» дип аталган дини-лирик эчтәлекле әсәре, «Чура батыр» «Җик-мәргән», «Түләк», «Түләк һәм Сусылу» дастаннары, «Таһир белән Зөһрә»нең Сәйяди һәм Кормаши вариантлары һ.б. укыйсы, өйрәнәсе килерлек итеп искә алынды. Кичәне алып баручы Зөлфәт Зиннуров, Резедә Сәләхова дастаннар турында кыскача мәгълүмат бирде, аларның өзекләреннән сәхнәләштерелгән күренешләр, музыкаль чыгышлар тәкъдим итеде.

Сөембикә КАШАПОВА.

Автор фотолары.

Авиация армиясе

Совет чорында данлыклы генерал Мөхәррәм Галимов турында ишетеп-белеп үстек. Мөгаен, моңа Чиләбе өлкәсенең Копейск каласында туган милләт баласының әнисе Хатирәнең Мамадыш районыннан булуы да этәргеч бирми калмагандыр. Гомумән, ул елларда Самат Шакир һәм Шамил Рәкыйпов кебек фидакяр затларның тырышлыгы белән, татар халкының каһарман ул-кызлары турындагы саллы язмалар бөтен татар дөньясына тарала торды. Тик, ни гаҗәп, чиксез мөмкинлекләр ачылган заманнарга керүгә, бу өлкәдә аңлатып булмастай тискәре хәлләр күзәтелә. Башка бик күп генераллар кебек үк Мөхәррәм Галимовның да Татар энциклопедиясенә кертелмәвен ничек аңлатырга? 2015 елда Михаил Черепанов редакторлыгында чыккан «Татарстан генераллары» исемле биографик сүзлектә дә, язмышлары турыдан-туры республика белән бәйле булган бик күп татар генераллары һәм адмираллары «онытып» калдырылган. Шул исәптән, әле Испания күгендә үк, фашистларга каршы сугышта күрсәткән батырлыклары өчен ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнгән очучы Мөхәррәм Нигъмәтҗан улы хакындагы язмага да урын табылмаган.

М.Галимов турында язучылар аның туган җирен ике төрле күрсәтә – Копейск каласы һәм Тугайкүл бистәсе. Бу хәлгә һич тә аптырыйсы юк, шахталарда эшләүчеләр каласы нәкъ менә әле узган гасырлардан ук мәгълүм булган Тугайкүл авылы урынында калкып чыккан. Сүз уңаеннан, 2010 елгы җанисәптә расланганча, Копейск каласы халкының 5,7 % ын, ягъни якынча 8 меңен татарлар тәшкил итә. Менә шушы, Чиләбенең юлдашы саналган калада 1907 елның гыйнварында шахтер гаиләсендә туган малай кечкенәдән хезмәтне үз итеп, физик яктан чыныгып үсә, максатчанлыгы, кыюлыгы, тәвәккәллеге, белемгә омтылуы белән дә яшьтәшләреннән аерылып тора. Әүвәл мәдрәсәдә сабак ала, аннары үзлегеннән әзерләнеп Чиләбе каласындагы урта мәктәпкә укырга керә, әмма гаилә ишле, әтисенең иңнәренә төшкән авырлыкны бераз булса да җиңеләйтү максатларыннан чыгып, Мөхәррәм җиденче классны тәмамлау белән, 16 яшендә шахтага эшкә чыга. 19 яше тулганчы, Копейск каласындагы 2 нче һәм 3 нче санлы шахталарда тир түгә. 1926-1929 елларда комсомол оешмасы юлламасы белән Свердловск каласындагы совет-партия мәктәбендә укый. Активлыгы белән аерылып торган егетнең ул чактагы Чиләбе округына керүче Катай районы (хәзерге Курган өлкәсе) комсомол комитеты секретаре вазыйфасына билгеләүләре һич тә гайре табигый түгел.

Милләттәшебез 1929 елның 20 сентябреннән – Кызыл армия сафларында: әүвәл Казандагы Татар-башкорт командирлар әзерли торган хәрби мәктәпне тәмамлый, аннары артиллерия полкындагы уку-укыту батареясында хезмәт итә. Полк мәктәбендә укыганнан соң, взвод командиры вазыйфасына билгеләнә. 1931-1933 елларда Ленинград каласында артиллерия мәктәбен тәмамлаган яшь командир хәрби хезмәтен 7 нче Самара кавалерия дивизиясе составындагы артиллерия полкында утка тоту взводы командиры буларак дәвам иттерә. Бер елдан лейтенант М.Галимов авиациягә күчә, ягъни кечкенәдән күңелендә төенләнгән хыялын тормышка ашыра –Оренбургтагы очучы-күзәтүчеләр мәктәбен тәмамлый һәм Көнбатыш хәрби округы составындагы аерым бомбага тоту авиациясе эскадрильясына юллама ала, хәрби өлкәдәге килчәге өметле командир самолет, звено, эскадрилья штурманы дәрәҗәләренә ирешә. 1937 елның декабрендә үз теләге белән Испаниядәге милли-революцион күтәрелеш чорында башланган гражданнар сугышына китә. Республика авиациясенең 24 нче бомбага тоту төркемендә эскадрилья командиры Андрей Стечишинның (псевдонимы «иптәш Анрес») штурманы итеп тәгаенләнгән Галимовның псевдонимы – «Родриго Мартинес». Совет лачыннары Алмания белән Италиядән килгән фашист очучылары белән чәкәләшә, аларның корабларын, җирдәге объектларын ракета һәм бомба утына тота. Милләттәшебезнең Испания коммунистлар партиясе җитәкчеләре Хосе Диас, Долорес Ибаррури һәм 12 нче интернациональ бригада командиры, язучы Матэ Залка белән берничә мәртәбә очрашып-сөйләшүе мәгълүм. (Әле тагын «генерал Лукач» псевдонимы белән дә билгеле булган һәм Австро-Венгрия империясендә яһүд гаиләсендә туган язучының чын аты – Бела Франкль). Мадрид, Барселона, Валенсия һ.б. испан калаларын фашистлардан яклап сугышкан М.Галимов исә ике Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә. Андрей Стечишинның Испания күгендә – 70, ә Галимовның 92 хәрби очыш ясаганлыкларын исәпкә алу да урынлы, димәк, милләт баласы башка очучылар белән дә күккә күтәрелгән.

Туган илгә әйләнеп кайткан ике Кызыл Байрак ордены кавалерын Кавказ арты хәрби округы штурманы вазыйфасына билгелиләр, ул 1939 елдан – майор, совет-фин сугышында катнашканнан соң, подполковник дәрәҗәсендә хезмәтен хәрби авиациядә дәвам иттерә. 1941 елда Төньяк Кавказ хәрби округының баш штурманы М.Галимов август-сентябрь айларында – Иранга каршы оештырылган походта, декабрь аеннан Бөек Ватан сугышында катнаша. Әүвәл фронтның хәрби-һава көчләре штурманы вазыйфасын башкара, ә инде 1942 елның гыйнвар-май айларында Кырым фронты штурманы, язның соңгы аеннан башлап сугыш тәмамланганчы – 5 нче һава армиясенең баш штурманы. 1942 елның 27 ноябрендә армия командующие авиация генерал-майоры Сергей Горюнов (1943 елның 28 маеннан – генерал-лейтенант, 1944 елның 25 мартыннан – генерал-полковник) үзенең баш штурманын I дәрәҗә Ватан сугышы орденына тәкъдим итеп, бүләкләү документын имзалый. Шул елның гыйнвар, март һәм июнь айларында армия күләмендә үткәрелә торган хәрби бурычларны үтәүгә саллы өлеш керткән, үзе дә ДВ-3 һәм Пе-2 самолетларында 5 шәхси хәрби очыш ясаган подполковник Галимовны бүләкләүне фронт командованиесе дә яклый. Чөнки Кырым, Кавказ арты фронтлары һәм 5 нче һава армиясе штурманнары белән ул җитәкчелек иткәндә, барлыгы 62 мең хәрби самолет-очыш вакытында нибары 45 тапкыр гына юнәлеше югалту теркәлә. Бу – юк дәрәҗәсендә аз! Бер генә аңлатма: генерал турында язылган бөтен хәрби чыганакларда да диярлек 5 нче һава армиясенең Төньяк Кавказ, Үзәк, 2 нче Украина фронтлары составларында булуы ташка басылган, ә бүләкләү документына имза салучылар – Кавказ арты фронты командующие армия генералы Иван Тюленев һәм Хәрби совет әгъзасы генерал-майор Константин Вершинин.

5 нче һава армиясе Кырым фронты хәрби-һава көчләре составындагы частьларның, берләшмәләрне һәм 15 нче авиаудар төркемен берләштерү нәтиҗәсендә 1942 елның июль аенда оеша. Әүвәл, Төньяк Кавказ фронты составында, Кавказ өчен барган сугышларда катнашкан армияне 5 октябрьдә Кавказ арты фронтына (2 нче формирование) кушалар. 1943 елның 4 февраленнән кабат Төньяк Кавказ фронтын (2 нче формирование) көчәйтә, ике ай ярымнан, сафларны тулыландыру өчен, Югары Башкомандование Ставкасына чыгаралар һәм Дала хәрби округы (9 июльдән – Дала фронты) составына кертелә, 20 октябрьдән җиңү таңы атканга кадәр 2 нче Украина фронтында сугыш хәрәкәтләрендә катнаша. Әлбәттә, бераз алгарак китеп, өчәр тапкыр Алтын Йолдыз белән бүләкләнгән Иван Кожедуб белән Александр Покрышкинның нәкъ менә шушы армия сафларында дистәләрчә дошман самолетларын мәтәлдереп төшерүләре турында искәртү һич артык тоелмас. Бөек Ватан сугышында 5 нче һава армиясенең 16 очучысы икешәр мәртәбә Советлар Союзы Герое исеменә лаек була, берәр тапкыр Алтын Йолдыз белән бүләкләнүчеләр саны – 174. Ул исемлектә татар милләтеннән булган Чистай егете полковник Әгъзам Вәлиев белән Чиләбе каласында туып үскән өлкән лейтенант Ибраһим Газизуллин да бар. Шунысы мөһим, Ибраһим Галим улының әнисе Фатыйха чыгышы белән Кукмара районыннан. Кызганыч, ике якташ очучының бер-берсен белү-белмәүләре турында мәгълүмат юк әлегә.

1943 елгы алышларда полковник дәрәҗәсе алган М.Галимов Украинаны һәм Молдованы азат итүдә, Румыния, Венгрия, Чехословакия һәм Австрия илләреннән фашистларны кууда катнаша. Фәкать 1944 елда Кызыл Байрак, Александр Невский һәм Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләнүен дә искәртү урынлы. Тыныч тормышта генерал белән очрашып сөйләшкән Самат Шакир ассызыклаганча, аның исемен ишетү белән алман очучылары радиоэлемтә аркылы: «Сак булыгыз! Һавада Галимов очучылары!» – дип бер-берсен кисәтә торган булган. Язучының

баш штурманы

„ЗА ВЗЯТИЕ ВЕНЫ"
УДОСТОВЕРЕНИЕ
За участие в героическом штурме и взятии ВЕНЫ
Полковник Галимов Мухарам Нигаметович
указом Президиума Верховного Совета СССР от 9 июня 1945 года награжден медалью
„ЗА ВЗЯТИЕ ВЕНЫ"
От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль вручена
13 АПРЕЛЯ 1945 г.
А № 083025

„ЗА ВЗЯТИЕ БУДАПЕШТА"
УДОСТОВЕРЕНИЕ
За участие в героическом штурме и взятии БУДАПЕШТА
Полковник Галимов Мухарам Нигаметович
указом Президиума Верховного Совета СССР от 9 июня 1945 года награжден медалью
„ЗА ВЗЯТИЕ БУДАПЕШТА"
От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль вручена
13 ФЕВРАЛЯ 1945 г.
А № 169911


ЗА НАШУ СОВЕТСКУЮ РОДИНУ!
СССР
УДОСТОВЕРЕНИЕ
За участие в героической обороне КАВКАЗА
Полковник Галимов Мухарам Нигаметович
Указом Президиума Верховного Совета СССР от 1 мая 1944 года награжден медалью
„ЗА ОБОРОНУ КАВКАЗА"
От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль „За оборону Кавказа" вручена 11 октября 1944 г.
0 № 002813

„ЗА ПОБЕДУ НАД ГЕРМАНИЕЙ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг."
УДОСТОВЕРЕНИЕ
За участие в Великой Отечественной войне
Полковник Галимов Мухарам Нигаметович
указом Президиума Верховного Совета СССР от 9 мая 1945 года награжден медалью
„ЗА ПОБЕДУ НАД ГЕРМАНИЕЙ В ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ 1941—1945 гг."
От имени Президиума Верховного Совета СССР медаль вручена

хаклыгын раслау өчен полковник Галимовны Кызыл Байрак орденына тәкъдим итеп тутырылган документка күз салу да җитә. Авиация генерал-лейтенанты С.Г.Горюновның 1943 елның 25 декабрендә имзалап, үз армиясенең баш штурманы полковник М.Н. Галимовка карата биргән бәяләмәсе тарих өчен теркәлеп калган: «Безнең һава армиясе частьлары 1943 ел дәвамында 71978 хәрби очыш ясады. Шул вакытта штурмлау частьларында нибары 213 мәртәбә юнәлешне югалту теркәлде. Очучылар составында ориентерларны югалтуларның шулай аз булуы частьларда штурман хезмәтенең дөрес оештырылуында, ягъни Галимов җитәкчелегендәге SOC хезмәтенең бик яхшы эшләвенә бәйле...

Белгород-Харьков операциясе вакытында, армиядәге штурман хезмәтенең яхшы эшләве нәтиҗәсендә, частьлар тарафыннан 12 мең самолет-очыш ясалуга карамастан, штурманнар гаебе белән югалтулар булмады. Операция дәвамында SOCның радиочыганаклары һәм яктылык маяклары 1000 сәгатькә якын өзлексез эшләп торды. Шул сәбәпле, күпчелек очракта, бомбага тотулар уңышлы тәмамланды».

Бу урында хәрби авиация штурманнарының, очучы-күзәтүче буларак (летнаб), навигациядән тыш, фотога төшерү, самолетка бомбалар тагу һәм аларны ташлау, ракеталарны төбәп ату кебек гаять җаваплы вазыйфаларны башкарулары да искәртү урынлы. Кайбер тип очу аппаратларында штурман әле самолет белән идарә итә белергә дә тиеш. 1944 елның 19 апрелендә 2 нче Украина фронты гаскәрләре буенча 16 югары чиндагы хәрбине Кызыл Байрак һәм Кызыл Йолдыз орденнары белән бүләкләү турында Боерык дөнья күрә. Фронт командующие Советлар Союзы Маршалы Иван Конев, Хәрби совет әгъзасы танк гаскәрләре генерал-лейтенанты Иван Сусайков һәм штаб башлыгы генерал-полковник Матвей Захаров кул куйган Боерыктагы Кызыл Байрак ордене белән бүләкләнүче 10 хәрбинең берсе – полковник Мөхәррәм Галимов. Бүләкләнүчеләр арасында 40 нчы армиянең элемтә бүлеге башлыгы, Украинаның Полтава өлкәсендә туган полковник И.И.Горелкин да бар. Әмма соңыннан элемтә гаскәрләре генерал-майоры дәрәҗәсенә үрләтелгән Исмәгыйль Исмәгыйль улы рәсми документларда, ни сәбәпледер, рус милләтеннән дип күрсәтелә.

Галимовның сугышта алган соңгы ордены белән бәйле кызыклы хәлләр күзәтелә. 1945 елның 4 июнендә 5нче һава армиясенең штаб башлыгы авиация генерал-лейтенанты Николай Селезнев полковник М.Галимовны III дәрәҗә Суворов орденына тәкъдим итеп, бүләкләү документын имзалый. Аннан күренгәнчә, «полковник Галимов... Будапешттан алып Алманиянең тулысынча җиңелүенә китергән барлык операцияләр барышында үз штурманнарының югары әзерлеген тәэмин итә. Будапештта камалышта калган алман гаскәрләрен тар-мар итүгә, каладан көньяк-көнбатышта башланып киткән дошман һөҗүмен кире кагуга һәм Братислава белән Брно калаларын басып алуга саллы өлеш кертә. Шул операцияләр тормышка ашырганда SOC хезмәте белән оста җитәкчелек итүе нәтиҗәсендә юнәлешләрне югалту очраклары бик аз теркәлә».

Әмма икенче көнне армия командующие генерал-полковник С.К.Горюнов документка үзгәреш кертә: тәкъдим ителгән орденны сызып ташлый һәм күпкә югарырак дәрәҗәдәге Кызыл Байрак орденына лаек дип кул куя. Әмма 2 нче Украина фронты Хәрби советында армиянең баш штурманын нибары тагын бер I дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләргә карар кылына. Фронт гаскәрләре буенча Боерык чыккан көн – 1945 елның 8 июне. Сугыштан соң, милләт баласы генерал-майор, армиянең баш штурманы һәм башка җаваплы вазыйфаларда хәрби авиациядә хезмәтен дәвам иттерә, СССРның атказанган хәрби штурманы буларак танылу таба, Ленин (1954), Кызыл Байрак (1950 һәм 1955), I дәрәҗә Ватан сугышы (1985) орденнары белән бүләкләнә. 1960 елның 17 декабрендә отставкага чыга, Украинаның Львов каласында яши, әмма кул кушырып утырмый: ДОСААФ системасында Кораллы көчләр өчен белгечләр әзерләүдә катнаша, сугыш ветераннары комитетының кала секциясе рәисенең беренче урынбасары булып сайлана. Яңа вазыйфасында эшләгәндә дә актив иҗтимагый тормышта кайный: Львовта һәм үзе азат иткән калаларда очрашуларда катнаша, фронтташ дуслары белән хатлар алыша, истәлекләр яза, гомумән, хәрби комиссариатларда, предприятиеләрдә, мәктәпләрдә һәм башка уку йортларында көтеп алынган кадерле кунакка әйләнә. Ленин, биш Кызыл Байрак, Александр Невкий, өч I дәрәҗә Ватан сугышы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм күп санлы медальләр кавалеры, 1 нче класслы хәрби штурман, авиация генерал-майоры М.Галимов 1990 елның 28 апрелендә Львов каласында вафат була.

Рәис ЗАРИПОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

6 май (шимбә). ***Шәүвәл аеның 16 нчы көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Чаян йолдызлыгында, 21.42 сәгатьтә калка, 4.36 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.39 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Нерв һәм эндокрин системаларга, күзгә игътибарлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Организмны чистарту (1)

Организмны шлаклардан чистарту өчен, дөрес туклану таләп ителә. 8 көнгә исәпләнгән биоген диета организмны “генераль җыештырып” кына калмый, тирене яңарту процессларын тизләтә, метаболизмны активлаштыра, күзәнәкләрнең туенуын җайга сала. Яшәртү өчен дә файдаланыла торган әлеге диета нигезендә барлык ашамлыкларны 4 төркемгә бүлү ята: 1) биоген (үсемлек орлык-төшләре, җиләк-җимеш һәм яшелчә соклары); 2) биоактив (чи яшелчә һәм җиләк-җимеш, чикләвек, әчетелгән сөт ризыклары); 3) биостатик (пешкән яшелчә һәм ярма, балык, ит, кош ите, диңгез ризыклары); 4) биоцид (рафинадланган һәм туендырылган-куертылган ризыклар, составында төрле буягыч, консервант, эмульгатор булган ашамлыклар). Диета вакытында 4нче төркемгә кергән ризыкларны куллану бөтенләй тыела, ә 3 нче төркемдәгеләрен куллану өлешчә чикләнә.

7 май (якшәмбе). ***Шәүвәл аеның 17 нче көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 23.15 сәгатьтә калка, 4.52 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.43 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Организмны чистарту (2)

1-2 нче көннәр. Иртән ач карынга – 1 стакан чиста чишмә суына ярты лимон согы һәм 1 чәй кашыгы бал кушып эчәләр. Көн буена яңа сыгылган яшелчә һәм җимеш соклары, бал белән үлән чәе эчәләр, әз генә җиләк-җимеш ашыйлар.

8 май (дүшәмбе). ***Шәүвәл аеның 18нче көне. 18 нче Ай тәүлегенең дәвамы. Ай Укчы йолдызлыгында, 0.38 сәгатьтә калка, 5.19 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.47 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору, төрле дәвалану чараларын куллану файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Организмны чистарту (3)

3-8 нче көннәр. Иртән ач карынга – 1 стакан лимонлы чишмә суы. Аннан соң 1 һәм 2 нче төркемгә кергән ризыкларны ашарга ярый: яңа сыгылган соклар, җиләк-җимеш, көнбагыш, көнҗет яки кабак төше өстәлгән яшелчә салатлары, үлән чәйләре хуплана. Боларны теләсә күпме ашау һәм эчү зыянсыз. 3 нче төркемгә кергән ризыклар

(Дәвамы 18 нче биттә).

Мәдәни җомга
5 май
№17, 2023

Айга кырын карама

– пешкән балык (бозау ите, кош ите), мичтә пешкән бәрәңге, шулай ук сыр һәм креветка белән сыйлану да рөхсәт ителә.

9 май (сишәмбе). *Шәүвәл аеның 19 нчы көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 1.40 сәгатьтә калка, 6.04 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.51 сәгать.*

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

10 май (чәршәмбе). *Шәүвәл аеның 20 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 2.30 сәгатьтә калка, 7.14 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.55 сәгать.*

Үз-үзеңне танып-белү, уйлану, буйсыну, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь.

Сары чыбык

Ревматизм, подагра булганда, бөер авырулары интектергәндә, бөердәге ком-ташларны чыгару өчен кулланыла. 6 чәй кашыгы вакланган сары чыбык (золотарник) үләнен 2 стакан салкын суда 8 сәгать төнәтәләр, сөзәләр, көненә 4 тапкыр яртышар стакан эчәләр. Эренле җәрәхәтләрне төзәтү өчен, яңа җыелган сары чыбыкны иттарткычтан чыгарып яки кипкән яфракларын порошок итеп төеп, бераз су кушып җебетеп, ярага ябалар.

11 май (пәнҗешәмбе). *Шәүвәл аеның 21 нче көне. 21 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 2.44 сәгатьтә калка, 8.45 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 15.59 сәгать.*

Сәяхәткә чыгу, теләсә нинди эш башлау өчен айның иң кулай көне. Кеше хәлиткеч карарлар кабул итәргә сәләтле. Физик эш белән шөгыльләнү, җәяү йөрү, чыныгу файдалы. Саф һавада күбрәк булу, табигать белән хозурлану кәефне күтәрә. Умырткалыкның аскы өлеше, әвернә сөяк, аяк зәгыйфь.

12 май (җомга). *Шәүвәл аеның 22 нче көне. 22 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 2.59 сәгатьтә калка, 10.24 сәгатьтә бата. 4 нче фаза. Көн озынлыгы 16.03 сәгать.*

Акыл җыю, белем алу, фәннәр өйрәнү көне. Юмарт булырга, ашау-эчүдә үзеңне чикләмәскә кирәк. Күбрәк аралашкан саен, яхшы тәэсирләр дә арта бара. Кан әйләнеше системасы, буыннар, умырткалык зәгыйфь.

Эремчекле көпшә

300 г эремчек, 200 г атланмай, 2 стакан он, чирек стакан шикәр оны, пычак очында тоз, сода, серкә кирәк. Йомшарган майны шикәр оны белән яхшылап изәләр. Он, тоз, эремчек, серкә белән сүндерелгән сода өстәп, камыр басалар. Икегә бүлеп, мөмкин кадәр юкарак итеп җәяләр. Түгәрәк җәймәләрне (торт кискән кебек) 16 шар өчпочмак килеп чыгарлык итеп кисәләр. Киңрәк ягыннан башлап, көпшә итеп төрәләр. Майланган табага тезеп, 200 градуслы газ мичендә 12 минут пешерәләр. Табынга куйганда, өстенә шикәр оны сибәләр.

Күпкырлы иҗат гаме

Әхәт дус Хәбибуллин яшьрәк чакта нефть өлкәсендә дә байтак еллар хезмәт куйган егет. Күптәннән уйлап йөргән, күрәсең, үзенә саваплы тагын бер шөгыль таба. Сөйләгәннәрдән генә китап язып булмый. Казан, Уфа, Мәскәү дәүләт архивларына барып элемтәгә керә, төбәк, авылы тарихына бәйле мәгълүмат туплый, язганда шуларны нигез итә. Борынгы актлардан, академик монографияләрдән файдалана. Тарихи китапның мөһимлеге шунда: үткәннәрне белергә кирәк, шунсыз киләчәкне күзаллау кыен.

Яшәеш турында язуга, нәсел шәҗәрәләре төзүгә әле генә керешә башладылар. Кем тумышы белән кайсы авылдан, шул турыда яза. Хәзер халык арасыннан чыккан, авыл-авыл дип өзгәләнгәннәр үзләре шушы эшкә алына. Бәлки шуңадыр, авыл тарихына бәйле китаплар күренгәли башлады. Габделәхәт үткәннәрдән алып бүгенгә хәтле араны үзе шул чорда яшәгәндәй бәйнә-бәйнә яза. Алдына куйган максатының мөһимлеген аңлый. Тарих язу тәҗрибәсе җитенкерәп бетмәсә дә, күләм ягыннан шактый калын, эчтәлеге белән тулаем алганда игътибарга лаек әсәр! Китап булып чыкканчы өзекләре Түбән Кама шәһәр һәм район газетасында күренгәли. Бер язма икенчесен тулыландырып, язылган бу әсәр авылдашлары күңеленә дә хуш килә. Кайберәүләр, мин үземнең әби-бабаларымны шушында таптым ди. Бу авыл бүген дә нәсел чылбырларын өзмичә яши бирә. Ә хәзер Габделәхәт, моннан соң авылга багышланган минекеннән дә яхшырак китаплар чыксын иде, ди. Табигать тә чиста, матур булсын. Җир шары ике миллиард ярым ел гына түгел, күбрәк яшәсен, алда инсаниятнең хыяллары зурдан әле, ди. Шушы – йөгерек тел белән язылган китап халыкка барып ирешә. Ул бу эшкә бик җаваплы карады, әдәби яктан камиллеккә җитkерергә омтылды. Авторның язу стиле кайбер очракларда укучы фикеренә тәңгәл килмәсә дә, күпләрне канәгатьләндерде. Әсәрдәге тарихи фактлар нәкъ Әхәтчә тасвирланган.

Язучылар белән кырык еллап элемтәдә. Махсус белеме булмаса да, каләмдәшем менә шундый китап язган, чыгарган икән, сөенергә кирәк. Авылдашлары да юкка гына Габделәхәткә рәхмәт сүзләре укымыйдыр.

Без бер чорда тудык, үстек, шәхес булдык. Кешене бит исән чакта хөрмәт итәргә, кадерләргә кирәк. Тәңрегә шөкер, күңелдә һаман авыллык. Затлылык та – шуннан. Безнең Әхәтебез яши-яши байтак язучыларны күреп белә. Күңелләре киң булгач, өйләренә дә килгәләп йөриләр. Андый чакта шигырь генә укымыйсың бит, җырлый ук башлыйсың. Габделәхәт иҗаты турында да иркенләп сөйләшерлек. Язучылар берлегенә кергәнче үк, «Ялгыш язмышлар» дигән роман язган егет ул. Темасы да тапталмаган – диңгезчеләр, үзе күргән илләр, дөньялар турында, безнең теш үтмәслек өлкә. Бик күпләр кебек эшмәкәрлеккә китеп тә әрәм булмады. Эшләсәң, эш барыбызга да җитәрлек, ди. Күпләр язучылыкны шигърияттән башлый, аннары прозага күчә. Әхәт дус башта роман язды, аннары авыл тарихын, аннан шигырь, поэма язуга керешә һәм берәүне дә кабатламый яза бирә. Һаман үз юлы белән бара, сүзнең төмен белә. Зарланмый, сыктамый, әйтәсен әйтә. Кыюлар гына сүзләрен сүз итә бит. Габделәхәт тә укучы кимеде дип тә күңелен сүрелдерми. Китап ул мең ел яши белә, алтынга тиң, әле булыр, дип үзен юата. Җәмгыятьтә иҗатка караш үзгәргән шушы чорда рухын төшермичә «Элекке кебек укый белгән буын туар, үсәр», – ди.

Сәҗидә Сөләйманова, Рафаил Төхфәтуллин исемендәге әдәби премияләр иясе милли җанлы дустыма бу язмам бер мәдхия булсын. Габделәхәткә дә мактау, зурлау сүзләре кирәк, ул да инсан – адәм баласы. Иҗатының чишмә башы Калатау итәгендә урнашкан Түбән Чаллы авылыннан, туган йорттан, ана теленнән башлана.

Самбо буенча СССРның спорт мастеры Әхәтнең йөзе-бите, фактурасы элек нык килешле иде, бигрәк тә офицер формасында. Ун ел нефть чыгарды, капитан погонлы хәрби, аннары ун ел диңгездә, ун ел эшмәкәр, директор. Эш, авыл дип, элегрәк әллә ничә машина туздырды. Бер генә лампочка янган урамын утлы итте, асфальт юклыгын Наиләсе белән ике ел исбат иткәч асфальт түшәделәр, сулы булды, телефон кермәгән иде, телефон керде. Хет бүгеннән үзе яшәгән Володарский урамын исән чагында ук Әхәт Хәбибуллин урамы ит.

Бүген дә нараттай әле Әхәт туган, уйлары да буталмый. Һаман нигә безнең халык хәсрәтсез яши белми, дип борчыла. Дингә кайтыгыз, туган телне онытмагыз, авылга юлны суытмагыз дияр өчен Әхәт булырга кирәктер. Халык, тел, дин дип яши. Кимибез дип еламаска кирәк, ди. Чыннан да, без югалырдай түгел, бетмибез болай гына.

Әхәткәй, сагышлардан, борчулардан, ничә тапкыр йөрәгең туктагандай булды. Җир шарында тәртип урнаштырасы, матурлыйсы иде дигән егетләр бу дөньяда сирәктер, аның өчен Әхәттәй булу кирәктер.

Язучылыкка тартылган кызы Әнисә «Татэнерго» тармагында юридик бүлек җитәкчесе, уллары шәхес булып киләләр. Спорт буенча да алда, иҗатка да битараф түгел. Бертуган Асия апаңның ике улы – Рифнур белән Илнур Түбән Кама районында, республикада иң-иң булдыклы фермерлар.

Менә бүген безнең буынга да алмаш кирәк. Җитмешкә җиткәнне сизми дә калганбыз. Тормыш дәрьясы саегып килә. Кыю, бер дигән егетләр үссен иде.

Гаиләдә уникенче бала булып ачлы-туклы елларда туса да юклы-барлы түгел ул Әхәт дус. Туган көнен дә сайлый белгән – 9 май, бик күп халыклар өчен иң кадерлесе. Һавада торна тавышы – кошларның кайтулары, күңелдә сагыш уятма көзләрнең җитүләре! Урамда яз. Урман, чокыр-чакырда апрель-май карына борын төрткән умырзаяларга сокланыйк. Әнә су буендагы таллар яфрак ярганчы чәчәккә төренгән. Хыялда булса да кайтып килик берәр тапкыр туташларга, ханымнарга, шаһинәләргә шәп бүләккә кушып чәчәк һәдия иткән чакка! Безгә генә язган бугай бер гомерлек сагыну. Бер очкыннан кабыну да мәхәббәткә табыну. Шушы хисләр гомер бакый җилкетә, яшәтә адәм баласын.

Зөфәр ДӘҮЛӘТОВ,
язучы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

Мәдәният йортларында

Кәҗә, сарык һәм башкалар...

Иске Кормаш мәдәният йортында оешкан «Тамчы» балалар театры коллективы Илгиз Зәйниевның «Кәҗә, сарык һәм башкалар» әсәрен юкка гына сайлап алмаган. Бу әсәр Тукай әкиятләренә нигезләнеп язылган. Әби белән бабай, чарасызлыктан, Сарык белән Кәҗәсен куып чыгарырга мәҗбүр була. Авылда, хуҗалары тәрбиясендә генә яшәгән йорт хайваннары тормыш авырлыклары каршында ялгызлары гына кала. Һәм менә шул кыен чакта сынала да инде дуслар. Алар бер дә югалып калмый, киресенчә, үзләренә бик күп дуслар да таба.

Менә шундый бик матур әсәр язган автор. Ә инде аны матур итеп сәхнәгә кую бик күп тырышлык сорый. Нәни артистларыбызга сәхнә серләрен төшендерген, аларга бик матур итеп костюмнар теккән Венера Хаҗиева, Рания Лортфуллина, ә сәхнәне нәкъ әкияттәгечә серле итеп бизәгән Ирек Хаҗиев, Рәмзил Шәяхмәтовларның хезмәте бик зур. Һәм әлбәттә инде балаларыбыз – нәни артистларыбызныкы! Абый-апалары өйрәткән һәр сүзне, һәр хәрәкәтне төгәл, тиешенчә итеп эшләргә тырышты алар. Нәтиҗәсе – авыл халкы алдында беренче зур имтиханнарын тоттылар һәм тамашачы күңелен яуладылар.

Ә алда аларны зур сәхнә, С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры көтә иде! Укучыларыбыз Роберт Шәймәрданов исемендәге республика мәктәп театрлары фестивалендә катнашу бәхетенә иреште. Сәхнә тутырып уйнаган 24 нәни артистыбызның барысы да үз рольләрен шундый оста итеп башкардылар. Тамашачыларыбыз аларны бик җылы кабул итте. «Көлдерделәр дә, елаттылар да», – дип үз сокlануларын белдерде алар. Балаларның сәхнәдә алган беренче чирканчыклары бушка китмәсен, дәвамлы булсын иде...

Гөлсәрия НӘГЫЙМОВА.
Актаныш районы, Иске Кормаш авылы китапханәсе.

Сәйдәш музеенда – Тукай моңнары

Быелның февраль аенда гына яшь драматург, талантлы иҗатчы Айдар Әхмәдиев белән С.Сәйдәшев исемендәге Зур концертлар залында куелган «Кави – Сәрвәр» операсы аша, либретто авторы булarak, танышкан идек. Шушы көннәрдә Айдар Әхмәдиев Татарстан Милли музее филиалы Салих Сәйдәшев исемендәге музейга директор итеп билгеләнде. Озак та үтмәде музей, 5-6 ел дәвамындагы озын тәнәфестән соң, әле рәсми ачылмаган булса да, эшчәнлеген башлап җибәрде. Анда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры оркестры белән берлектә «Тукай моңнары» исемле концерт узды. Музыкаль кичә бөек шагыйрьнең туган көненә һәм Татарстанның халык артисты Эмиль Җәләлетдиновның якты истәлегенә багышлап үткәрелде.

Концерт Эмиль Җәләлетдинов турында хатирәләр белән үрелеп барды. К.Тинчурин театры оркестры солисты, Халыкара конкурслар лауреаты Айгөл Зәйнуллина 20 ел дәвамында Эмиль Җәләлетдинов белән бергә эшләгән, аның концертмейстры булган. Ул моны язмышының бер бүләге дип саный. «Олуг җырчыбыз минем кумирым иде», – ди ул. Айгөл соңгы елларда Эмиль ага белән Казан музейларында, мәктәпләрендә чыгыш ясаган. «Аның халкыбызның моңнарын бик яратып башкаруын тыңлап кинәнә идек. Сәхнәгә чыгып соңгы җырлаулары, узган елгы Габдулла Тукайга багышланган зур концерты аеруча истә калды. Шунысы гаҗәп иде, 79 яшендәге өлкән кеше җырларның бер генә сүзен дә онытмый, кулына берниди язулар тотмыйча башкарып чыга. Узган ел Татар китабы йортында соңгы концертны куйдык», – ди А.Зәйнуллина. Ул үзе дә Э.Җәләлетдинов ярдәмендә татар классик музыкасы – композиторларыбыз Рөстәм Яхин, Алмаз Монасыйпов, Мансур Мозаффаров һ.б.ның гаҗәеп гүзәл әсәрләре белән тирәнрәк таныша. Эмиль агада барлык җырларның кулдан язылган ноталары була. Соңгы елларда ул үзе дә шигырьләр һәм көйләр иҗат итә башлый. Оркестрның баш режиссеры, талантлы композитор һәм музыкант, Муса Җәлил исемендәге премия лауреаты Ильяс Камал аның күп кенә җырларына аранжировка ясаган. Айгөл Зәйнуллина Эмиль аганы затлы, киң күңелле, кешенең уңай сыйфатларын гына күрә, беркем турында да начар сүз әйтми, беркайчан да күңелен төшерми торган кеше булып хәтерендә калуы турында сөйләде. «Ул бу дөньяга яктылык, изгелек китерергә килгән кеше кебек иде», – диде ул.

Ильяс Камал Э.Җәләлетдиновның җырларын фортепианода эшкәрткән, аларга бергәләп чыгышлар да ясарга туры килгән. Ул Эмиль аганы татар музыкасын, җыр сәнгатен күтәрүдә күп эшләгән, тирән эз калдырган шәхес буларак искә алды. Узган сезонда Тинчурин театрында «Татар музыкасы җәүһәрләре» дигән яңа проект башланып киткән. Анда җырчының оркестрга кушылып чыгыш ясавы хәтерләргә истәлек булып уелган. Алмаз Монасыйпов иҗат иткән, татар музыкасының алтын фондына кереп калган «Тукай аһәңнәре» вокал-симфоник циклын да беренчеләрдән булып Эмиль ага башкарган. Композиторның шушы әсәре өчен Тукай премиясенә лаек булуын хәтерлибез әле.

Концертта, оркестрга кушылып Салих Сәйдәшев исемендәге дәүләт Зур концерт залының солисты, Халыкара конкурслар лауреаты Илгиз Мөхетдинов «Тукай аһәңнәре» вокал-симфоник циклының «Туган авыл», «Белмәдем», «Татар яшьләре» дигән өч кисәген башкарды.

Зур талант иясенең тормышы елекэлектән бормалы һәм катлаулы булган. Без моны Г.Тукай һәм С.Сәйдәшев мисалында күрә алабыз. Алмаз Монасыйповка да рәсми оешмалардан бик күп тәнкыйть сүзләрен ишетергә туры килә, күп әсәрләре тыела. «Тукай аһәңнәре»н Эмиль Җәләлетдиновның дәрәҗәсе саклап калгандыр», – ди Айдар Әхмәдиев.

Концертта «Тантана» премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган артисты Эльза Исламова композитор Миләүшә Хәйруллина Г.Тукайның «Яратма» дигән шигыренә язган җырын беренче тапкыр башкарды. Концертта К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры оркестры солисты, баянчы Алмаз Ахуновның гармунда, Ильяс Камалның кыл-кубызда халкыбыз моңнарын гаять оста яңгыратуы да сокландырды.

«Музейның киләчәген шулай дустанә, җылы кичләрне бергәләп үткәрүдә күрәбез. Шулай ук Казандагы иҗат коллективлары, яшь артистлар белән җылы мөгамәләдә торып, милли музыка, мәдәниятебезне үстерүдә бергә эш алып барырга хыялланабыз», – диде Айдар Әхмәдиев. Хәзерге вакытта залларда экспозицияләр корыла. Музейның булдырылуына 30 ел тулган көнне – 25 июньдә рәсми рәвештә ачарга әзерләнәләр.

Концертның тагын бер матур истәлеге – Казан театр училищесы студенты Данис Хисмәтуллин Г.Тукай шигырьләрен укыды. Музыкаль кичәне музей директоры Айдар Әхмәдиев алып барды.

Сөембикә КАШАПОВА.
Автор фотолары.

МК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

5 май – Шәрык клубында 18.00 – «Артист» (Г.Кариев). 19.00 – «Җанкисәккәем» (Т.Миңнуллин).
6 май – Шәрык клубында 15.00 – балалар өчен рәсем дәресе. 18.00 – «Сәфәр» (А.Шакиров).
7 май – 12.00, 12.30 – «Дәрсе гыйбрәттер театр...» (Р.Мөхәммәтшин). 18.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
8 май – «Исәнме, улым!» (Б.Абдуразззоков).
10 май – Кече залда 17.00 – «Сагынабыз Сезне...» (Н.Ихсанова һәм Н.Дунаевны искә алу кичәсе». 19.00 – «Татармультфильмның «Әлдермештән Әлмәндәр» мультфильмын күрсәтү». (Т.Миңнуллин).
11 май – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).
12 май – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

6 май – «Аида» (Дж.Верди).
12 май – «Спящая красавица» (П.Чайковский).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

6 май – «Яратам! Бетте-китте!» (Л.Әминова).
7 май – «Аферист» (Н.Исәнбәт).
10 май – «Карурман» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).
11 май – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова).
12 май – «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

7 май – «Хәтер» дип исемләнгән язгы концерт.
11 май – «Мио, минем Мио!» (А.Линдгрен).
12 май – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

5 май – зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән), кече залда – «Мактанчык этәч» (Аманулла). 19.00 – «Shurale: яңа фантазия» (Ф.Яруллин).
6 май – «Маугли» (Р.Киплинг әсәре, Р.Таһиров инсценировкасы).
7 май – Зур залда – «Русалочка» (Г.-Х.Андерсен), кече залда – «И, кызык Шүрәле!..» (Г.Зәйнашева).
8 май – Зур залда – «Аладдин» (гарәп әкиятләренә нигезләнгән), кече залда – «Серая шейка» (Д.Мамин-Сибиряк).
9 май – Фойеда – «Приключения пингвиненка Пинка» (А.Галиуллина). Зур залда – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәре буенча).
12 май – 12.00 – «Страна чудес Алисы» (Л.Кэрролл әсәре буенча). 19.00 – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

10 май – Татар эстрадасы коцерты. Катнашалар – Г.Асаева, Р.Фазлыәхмәтов, Н.Нигъмәтуллин, Г.Идрисова, И.Баһ.
12 май – Үзбәкстанның «Бахор» дәүләт бию ансамбле концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

12 май – Р.Абязов җитәкчелегендәге La Primavera Казан камера оркестрының танылган композитор С.Рахманиновның 150 еллыгына багышланган «Ак сирин рыцаре» дип исемләнгән концерты.

Соңгы сый

АКШта үлем җәзасына хөкем ителүченең соңгы сүзгә һәм соңгы сыйга хокукы бар. Штат законы рөхсәт иткән очракта кайбер җинаятьчеләр әллә нинди ресторан сые да таләп итә ала, бары алкоголь һәм сигара гына рөхсәт ителми. Бик кыйбатлы ризык таптырсалар, төрмә администрациясе аның ингредиентларын арзанлырагына алыштырырга хокуклы. Теннеси штатында кеше үтергән өчен хөкем ителгән Филипп Уокер, бик зур вегетариан пиццасына заказ биреп, аны сукбайлар белән бүлешергә теләгән, тик төрмә җитәкчелеге аның ихтыярын үтәүдән баш тарткан. Әмма штатның хәйрия оешмалары ул җәзалап үтерелгән көнне йорт-җирсезләрне йөзләрчә пицца белән сыйлаган. Флоридада соңгы ашка кирәкле барлык ашамлыклар штат территориясендә сатып алынырга, бәясе исә 40 доллардан артмаска тиеш. Гадәттә бу тәгам кыздырылган ит кисәгеннән, йомырка тәбәсеннән, коймактан, майлы һәм джемлы тостлардан, сөт һәм соктан гыйбарәт. Мэриленд штатында тоткынның капризларын үтәп тормыйлар, аңа бөтен кешегә әзерләнгән кичке ашны гына бүләләр. Техас хакимиятендә үтерелүчене сыйлау традициясе 2011 елда Лоуренс Расселл Брюер аркасында бетерелгән. Тоткын искиткеч туклыклы кичке ашка заказ биргән: ике кисәк тавык ите, "өч катлы" чизбургер, тапалган сыер ите белән йомырка тәбәсе, помидор, татлы борыч, халапеньо борычы, кетчуп белән бер җамаяк бамия кузагы, бер кирпеч ак икмәк белән ярты килограмм грильдә кыздырылган сыер ите, өч фахита, итле пицца, бер чиләк туңдырма, арахис мае белән чикләвекле ирис, өч стакан рутбир (тамыразыклардан төрле тәмләткечләр кушып кайнатылган сыра). Барысын да әзерләп, Брюерны табынга чакыргач, ул, "мин ачыкмадым әле" дип, баш тарткан. Җәнҗал штат сенаторы Джон Витмирга барып ирешкән, халыкта ризасызлык тудырган һәм хакимиятне катгый адым ясарга мәҗбүр иткән.

("The Washington Post").

Көненә – 200 энҗе

Энҗе эзләү куркыныч кәсепләрдән санала, ул үзенчәлекле күнекмәләр һәм осталык таләп итә. Һөнәр серләре буыннан-буынга тапшырыла. Энҗе, җир астында ясала торган асылташлардан аермалы буларак, ике якка ачылмалы моллюск кабырчыгы эчендә барлыкка килә. Ул – моллюск организмының саклагыч реакциясе нәтиҗәсе. Кабырчыкка ком бөртеге эләккәч, организм чит предметны перламутр катламнарына "төрә" башлый, шулай энҗе шарчыгы ясала. Аеруча сыйфатлы энҗе диңгез моллюскларында барлыкка килә. Аны эзләп моннан 4 мең ел элек үк су астына төшә торган булганнар инде. Иң күп энҗе Кызыл диңгездә, Фарсы култыгында, Цейлонда, Таитида, Һиндстан һәм Иран яр буйларында табыла. Энҗе эзләүчеләр диңгез төбенә көймәгә бәйләп куелган таш ярдәмендә төшә. Көн буена алар 40-50 тапкыр су астына төшәргә һәм 200 кабырчыктан энҗе җыярга мөмкин. Энҗе эзләүчеләр су астында 50-80 секунд тора. Балаларны 7-8 яшьтән өйрәтә башлыйлар, 15 яшьтә инде алар өлкәннәр белән беррәттән чума. XX гасыр уртасына кадәр энҗе эзләүчеләр суга кулларына пычак тотып кына төшкән, хәзер махсус костюм һәм битлек киеп чумалар. Әмма элеккечә үк эзләүчеләр дә бар. Алар 30 яшьтә инде картлар кыяфәтенә керә, күзләре начар күрә, куллары калтырый, колаклары ишетми, тик башка һөнәр сайларга мөмкинлекләре булмаганга, ата-бабалары кәсебен дәвам итәргә мәҗбүр.

("Daily Mail").

Ньютон тәкъдиме

Баштарак акчаның бәясе андагы металл микъдарына тәңгәл булган. Һәм андый акчаларның кырыйларыннан алтын һәм көмешне кырып алучы каракларда озак көттермәгән. Бөтен кеше үзе белән үлчәү күтәреп йөрмәгән, күз белән генә төгәл билгеләү дә мөмкин булмаган, шунлыктан мондый алдакчыларны эләктерә алмаганнар. Әлеге проблеманы сэр Исаак Ньютон хәл иткән, чөнки ул физик кына түгел, Британия Король акча сугу йорты хезмәткәре дә булган. Ул тәңкә кырыйларын киртләргә тәкъдим иткән, бу сырлар янында кырып алынган урыннар шундук күзгә ташланырга тиеш булган. Әлеге киртләү процедурасы, хәзер инде кирәге булмаса да (чөнки ялган купюралар ясау моннан файдалырак һәм җиңелрәк), хәзергә кадәр сакланган. XVI гасырның икенче яртысында исә французлар тимер тәңкәләрнең кабыргасына язу төшерү җайланмасы уйлап тапкан. Беренче язу алтын экю сыртында 1577 елда пәйда булган.

("Die Presse").

Зиратсыз шәһәр

